Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 46 (1411) 25 ноябрь 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga



12

Моңарчы аны агачтан уючы, балчыктан әвәләүче, шагыйрь булап белсәк, “Хәзинә” галереясында рәсем сөючеләр Хәмит Латыйповны башка яктан ачты.

14

Казанда имам-хатыйб Йосыф хәзрәт Дәүләтшин фикердәшләре белән бергә бик саваплы эш – мохтаҗларга бушлай ризык тарату эшен оештырып җибәргән.

16

Теләсә кайсы сәхнәдә сопрано тавышы белән микрофонсыз акапелла җырлый ала ул – Татарстанның атказанган артисты Гөлшат Имамиева.

Газиз әнкәйләрнең кочагында
Без гомергә сабый баладыр...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанда яшәүче Гөлүсә Закированы «Ел китапханәчесе – 2022» Бөтенроссия бәйгесендә җиңүе белән котлады.
- Россия Композиторлар берлеге идарәсе рәисе, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Рәшит Кәлимуллин Адыгеяның атказанган сәнгать эшлеклесе исеменә лаек булды.
- Россиякүләм «Озын тәнәфес» бәйгесендә җиңеп, Татарстан көллиятләренең дүрт студенты берәр миллион, өч студент ике йөзәр мең сум сум акча отты.
- Башкорстанның Тәтешле районында Хәния Фәрхигә куелган һәйкәлне, әйләнә-тирәсен тәртипкә китерү кирәклеге сәбәпле, урыныннан алганнар.
- «Созвездие – Йолдызлык» арт-резиденциясе Балтач мәдәният йортында «Ерак йолдыз яктысы» дип аталган татар телендә беренче спектаклен күрсәтте.
- Татарстан Журналистлар берлегендә күренекле публицист Марсель Зариповны искә алып, аның Түбән Кама шәһәре турында китабын тәкъдим иттеләр.
- Чита шәһәрендә Рәхмәтулла Нигъмәтуллинның 1900 елда төзелгән, Җәмигъ мәчете комплексына кергән агач йортына реставрация ясалды.
- «Татарлар Италиядә» мәдәни ассоциациясе Римда яшәүче милләттәшләребез өчен опера җырчысы Диана Нурмөхәммәтова концертын уздырды.
- Бүген Милли китапханәдә Татарстан халык шагыйре Рөстәм Мингалимгә багышланган әдәби музыкаль кичә була.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Разил ВӘЛИЕВ, Татарстанның халык шагыйре:

«Тел мәсьәләсе кайбер кешеләргә гади кебек, әмма гади түгел икән шул. Шуңа күрә телебезгә бик тә сак карарга, үзебездән мөмкин булган кадәр өлеш кертергә тиешбез. Дөрес, бик күп нәрсә бездән генә тормый. Бездән торган нәрсәләр дә бар. Әлеге дә баягы – балаларны татар гореф-гадәтләренә, татарча сөйләшергә өйрәтү, татарча тәрбияләү. Әгәр дә кеше: «Әмин милләтне саклау өчен нәрсә эшләдем?» – дип үз-үзенә сорау бирсә, милләтебезнең язмышы яхшы якка үзгәрер иде».

СЫНАМЫШЛАР

25 ноябрьдә яңгыр йә кар яуса, 4 декабрьгә кадәр көннәр җепшек тора ● 27 ноябрьдә яңгыр яуса, киләсе елда бодай уңа; агачларны бәс сарса, солы уңа ● 29 ноябрьдә көчле җил иссә, 19 декабрьгә кадәр буран котыра ● 1 декабрьдә һава торышы нинди булса, кыш буена шундый була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 37 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 22 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 45 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **20 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **2 декабрьдә 7 сәгать 25 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

25 ноябрь – Язучы Хәйдәр Гайфетдин улы Гайнетдиновның тууына 70 ел (1952–2000);

– Скульптор, гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Асия Миңневәли кызы Миңнуллинага 70 яшь (1952).

26 ноябрь – язучы, филология фәннәре кандидаты Рөстәм Госман улы Галиуллинга 35 яшь (1987).

28 ноябрь – күренекле совет дипломаты һәм иҗтимагый-сәяси эшлеклесе Кәрим Габдрәүф улы Хәкимовның тууына 100 ел (1922–1994).

29 ноябрь – язучы, журналист, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әхәт Хәбри улы Фазылҗановның тууына 95 ел (1927–2009).

30 ноябрь – Казан дәүләт яшь тамашачылар театры ачылуга 90 ел (1932).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Ноябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 25 ноябрь (җомга).**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(24-30 ноябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **25 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр** бөер һәм бәвел куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны нығыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген җөмәдел әүвәл аеның 1 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Рүзәл ЮСУПОВ, академик

ТОЛЕРАНТЛЫК – ЮЛ КУЮ ТҮГЕЛ

Татарстанның Югары Советы тарафыннан республикабызның яңа төп законы – Конституциясе кабул ителүгә (06.11.1992 ел) 30 ел булды. Бу зур вакыйга аеруча истәлекле гамәлләрем белән бәйләнешле. Миңа, ул законның проектын әзерләгәндә, тикшергәндә һәм парламент сессиясендә кабул иткәндә, Югары Советның милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиясенең (хәзергечә комитетының) рәисе һәм Конституция комиссиясе әгъзасы буларак, актив катнашырга туры килде. Татарстанның бу яңа Конституциясе – республикабызның ирекле, демократик үсешенә ныклы нигез салуга юнәлтелгән гаять әһәмиятле документ. Аның беренче абзацы – Преамбуласы ук чын цивилизацияле җәмгыятьнең төп законы булуына ишарә итә: «Бу Конституция Татарстан республикасының дәүләт статусы турында халыкның тавыш бирүе (референдум) йомгаклары нигезендә кабул ителә һәм игълан ителә». «Иҗтимагый-сәяси система» дигән бүлектәге беренче маддә исә халыкның күңелендә күп гасырлар сакланып килгән өметенең акланачагына ышаныч уята: «Татарстан республикасы – җөмһүриятнең күп милләтле халкының ихтыярын һәм мәнфәгатьләрен чагылдыра торган суверен демократик дәүләт».

Төп закон нык уйлап төзелгән һәм, ул катгый рәвештә үтәлгән очракта, республиканың уңышлы алга баруына, халыкның бәхетле яшәвенә хезмәт итәргә тиеш иде, әмма өметләр акланмады. Алдагы чакырылыш депутатлары, сыек буынлы булулары һәм үзәк хакимияте басымы аркасында, төп законны 16 тапкыр (!) үзгәртте һәм нәтиҗәдә беренче тапкыр кабул ителгән Конституциянең шактый әһәмиятле маддәләре алмаштырылды һәм алып ташланды.

Әле бүгенге хәлдәге Конституция тулысынча үтәлсә дә, ярыйсы булыр иде, юк шул. Безнең республика Конституциясенең, Россиянеке кебек үк, байтак мөһим статьялары үтәлми. Шуның аркасында бигрәк тә милли мәгарифкә, аеруча балаларга һәм яшьләргә туган телләрен өйрәнү эшенә зур зыян килә. Мисал өчен, Татарстан Конституциясендәге 34 нче статьяның 2 нче пунктын карыйк. Анда «Һәркемнең туган телен куллануга, үзе теләгән телдә аралашырга, балаларын укытырга һәм тәрбияләргә хокукы бар» диелгән. Исебезгә төшерик: бездә һәр кеше үз сабыен татарча тәрбияләнә торган балалар бакчасына бирә аламы? Татар ата-аналарының барысының да балаларын саф татар мәктәпләрендә укыту мөмкинлеге бармы? Бу сорауларга уңай җавап юк. Татарча тәрбия бирә торган бакчалар республикада бармак белән генә санарлык. Үзәктән килгән әмер буенча, җирле хакимият вәкилләренең дәшмичә генә риза булуы нәтиҗәсендә татар телендә белем һәм тәрбия бирә торган мәктәпләр кими. Милли уку йортларында чыгарылыш (дәүләт) имтиханнарын русча бирү тәртибе кертелгәнлектән, татар мәктәпләре рус телендә укытуга күчә. Хәзер инде татар авылларындагы балалар да үзара күбрәк русча аралаша. Безнең парламентта татар телен укытуга вакытны атнасына ике сәгать белән генә чикләргә дигән карар кабул ителеп, бу карарның үтәлешен прокуратура вәкилләре тикшереп йөри башлаганнан соң, татар телен укыту мөмкинлекләре аз гына калды. Шуның өстенә, Россиянең мәгариф министрлыгы әзерләгән дәүләт стандартларында туган телләрне укыту вакытын тагын бермә-бер киметү, ә кайбер сыйныфларда бөтенләй бетерү күздә тотыла. Шулай итеп, руслардан башка балаларга туган телләрен укытуны юкка чыгарырга җыеналар. Россия Федерациясенең, Татарстан республикасының Конституцияләре, Россиянең мәгариф турындагы законы бөтенләй исәпкә алынмый. Баксаң, Россия Федерациясенең мәгариф турындагы законының 6 нчы статьясының 2 нче пунктында менә ничек язылган: «Гражданнарның туган телләрендә белем алуы тиешле санда мәгариф учреждениеләре, класслар, группалар, шулай ук кирәгенчә шартлар булдыру юлы белән гамәлгә ашырыла». Әйтергә оят: хәзер хәтта туган тел һәм әдәбият дәреслекләрен Мәскәү раслаганнан соң гына, ягъни шуның ризалыгы белән генә бастырып чыгарырга мөмкин бит! Республикалардагы мәгариф министрлыкларының нинди генә вәкаләтләре һәм хокуклары калган икән соң? Алар әллә Россия Федерациясенең мәгариф турындагы законындагы 6 нчы статьяның 3 нче пунктын белмиләрме икән? Анда болай язылган лабаса: «Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрен өйрәнү мәсьәләләре бу республикаларның законнары белән хәл ителә».

> ***«Безнең хокукларыбыз гаранты булган конституциянең үзенең генә гарантиясе юк».***
>
> **Валерий ФИЛАТОВ,**
> **актер.**

Ни өчен Татарстан хөкүмәте милли мәгарифнең хәлиткеч мәсьәләләрен, иң әһәмияте вазыйфаларын тыныч кына Мәскәүгә биреп бара икән? Яшәү өчен мөһим мәсьәләләр белән республика үзе шөгыльләнергә тиеш бит югыйсә. Рухи тормышның, мәдәният, мәгарифнең барлык проблемаларын да үзәктән килгән күрсәтмәләр, директива һәм инструкцияләр буенча гына хәл итәрлек булгач, республика органнарының һәм республиканың үзенең дә кирәге каламы соң? Татарстан үзенең республика икәнлеген ничектер акларга тиештер бит. Татарстан Республикасының, 100 ел яшәгәннән соң, хәтта дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул итеп, аның нәтиҗәләрен референдум белән раслаганнан соң, куәтле икътисадлы, үзәккә һәр елны триллионга якын сумлык табышын биреп барган республиканың үзенең мәгарифе, мәдәнияте мәсьәләләрен үзе хәл итәрлек мөмкинлекләре һәм хокуклары да калмаганмы икән соң инде?!

Чаң сугар вакыт җитте, туган телне саклау өчен дип, ярым-йорты нәтиҗәле, сүз өчен генә чаралар күреп, тынычланып һәм кешеләрне дә тынычландырып йөрер чак түгел. Мең еллык әдәбият иҗат ителгән әдәби телебезне, бөтен милли мәдәниятнең, алга киткән халыкның уңышлы яшәешенең нигезен тәшкил иткән телне милли мәгарифне, җанландырып, тиешле югары дәрәҗәгә куймый торып саклап калу мөмкин түгел.

Республика җитәкчесенең абруен, парламент һәм хөкүмәтнең тырышлыгын бергә туплап, Дәүләт Думасындагы Татарстаннан сайланган депутатларны җәлеп итеп һәм башка республикалар хакимиятләре белән бердәмлеккә ирешеп, Россия Президентына һәм Дәүләт Думасына шундый таләпләр белән мөрәҗәгать итү зарур: республикаларга рухи тормыш, барыннан да бигрәк милли мәгариф, мәдәният мәсьәләләрен үзләре хәл итү хокукы бирелсен, яшь буын туган телен, әдәбиятын, мәдәниятен һәм тарихын, башка мәктәп предметларын өйрәнгән кебек, яхшы итеп үзләштерерлек шартлар тудырылсын. Бу – заман таләбе.

МӘҖ Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Упкын читендәге тигезләнеш

Җил чәчсәң, давыл урырсың, дигәннәре хактыр, күрәсең. Чөнки махсус хәрби операция дулкынында башланган кайбер вакыйгалар сөреше инсаниятне бүген хәтта атом-төш упкыны читендә тигезләнеш тотарга да мәҗбүр итә. Ә моңа китергән сәбәп бик тә үзенчәлекле булып чыкты: Россия энергетика инфраструктурасы объектларын ракета утына тота башлагач, ике ракетаның ни сәбәпледер Польша территориясенә төшүе мәгълүм булды. Ни гаҗәп, мөһим объектларга әлеге тупланышлы һөҗүм шунда ук онытылды һәм бөтен игътибар Польшага очып кергән ракеталарга, аларның кемнеке икәнен һәм максатын ачыклауга күчте. Чөнки бу ил – НАТО әгъзасы. Ә аның уставы (5 нче маддә), альянс әгъзасына һөҗүм башланса, күмәк саклануны күздә тота. Чикне Украина саклану системасы җибәргән С-300 ракетасы үтүе ачыклангач, кискен хәл бераз йомшады да кебек. Тик монда бер нәрсә ачыкланмыйча калды: С-300 һава һөҗүменә каршы кулланыла, димәк, чик аша ул башка ракетага ияреп кенә керә ала. Тик бу хакта сүз булмады. Ә G20 саммитында кабул ителгән декларациягә килгәндә, анда инде климат, энергетика һәм валюталар курсы проблемалары телгә алынган һәм атом-төш коралын куллануга юл куярга ярамавы турында әйтелгән. Төп каршылык исә Украинадагы хәлләр һәм Россиягә карата мөнәсәбәт тирәсендә килеп чыккан. Кытай, әйтик, Россияне G20дән чыгаруга каршы, әмма хәрби операцияне туктату яклы булуын белдергән. Документта исә, гәрчә G20 әгъзаларының күпчелеге Россияне кискен гаепләве турында әйтелсә дә, Мәскәү таләбе белән анда «башка фикерләр дә булды» дигән гыйбарә дә өстәлгән. Мәскәү әлеге декларацияне «аек фикернең җиңүе» дип бәяли.

Геосәяси вәзгыятьнең асылын чамалау һәм якын киләчәкне дә фараз кылу өчен, әүвәл төп уенчыларның реаль хәленә кыскача тукталып үтик. Кушма Штатларда хакимият дөнья тотучылар файдасына эшли торган ике партияле (демократлар һәм республикачылар) сәяси системага корылган. Соңгы арадаш сайлауда Вәкилләр палатасында гади (8 урын) өстенлек белән республикачылар җиңде, ә палата спикеры демократ Н.Пелоси (аңа 82 яшь) гыйнварда вазыйфадан китәчәген әйтте. Сенатта исә өстенлек демократларда кала. Ә сайлау системасы бу илдә шулай итеп корылган ки, сайлаучылар анда хактан да икенең берсен сайлый ала. Нәтиҗәдә, халык та «пар» чыгарып ала, дөнья тотучылар да канәгать. Ә 2024 елда президент сайлавына республикачы Д.Трамп та чыга. Димәк, демократ Байден өчен бу инде икенче срокны да реаль мөмкинлеккә әйләндерә. Тик партиядәшләре президент итеп траптан менгәндә абынып егылмый торганрак кешене дә күрергә тели кебек. Ә дөньяда гегемонлыкны әлегә АКШ тота. Узган атнада Джо Байден, АКШ әле күп еллар глобаль икътисадта лидерлыкка әзер, дип белдерде. Дөнья белән идарә итүнең финанс механизмы да әлегә аларда. Әмма АКШның тышкы әҗәте бүген инде 31 триллион доллардан артып киткән (аның иң зур өлеше Кытайга туры килә) һәм ул дөньякүләм әчке тулай продуктның чиреген тәшкил итә, ягъни ул бөтен дөнья хисабына яши булып чыга. Акча калыбы аның үзендә, димәк, долларны да ул кирәк кадәр чыгара ала. Илнең хәрби бюджеты бүген инде 813,3 миллиард долларга җиткән (2021 елда: Кытай – 293 млрд $; Һиндстан – 76,6 млрд $; Бөекбритания – 68,4 млрд $; Россия – 65,9 млрд $).

Кытай да алга бара. Анда бер партияле сәяси системага корылган тоталитар режим хөкем сөрә. Илнең төп үсеш юнәлешләре исә Кытай коммунистлар партиясенең әле күптән түгел генә үткән XX съездында билгеләнде: интеграциядә, товарны «күмәк Көнбатыш»ка экспортлауга корылган икътисад моделеннән баш тартып, «Бер пояс – бер юл» башлангычын киңәйтүгә булган әчке ихтыяҗны җәелдерү стратегиясенә күчү; «кытай милләтен зурдан торгызу» программасын «яңа үсеш моделе» һәм «кешелек цивилизациясенең яңа формасы» аша гамәлгә ашыру; бу модельне заманча югары технологияләргә таянып тәкъдим итүдә һәм аларны комплекслы куллану вә үстерүдә Кытайның дөнья лидерлыгына ирешүе. АКШ һәм Кытай атом-төш коралын куллануга каршы чыкты. КХР лидеры Си Цзиньпин исә, ике илнең үсүе һәм чәчәк атуы өчен дөньяда урын җитәрлек, дип тә әйтте. Димәк, сүз «ике полярлы» дөнья турында бара. Ә бездә «күп полярлылык» турында да сүз куерткannar иде.

Фоат УРАЗАЙ.

Иң югары бүләк

Танылган астрофизик, Россия Фәннәр академиясе һәм Татарстан Фәннәр академиясе академигы Рәшит Сөнәев теоретик физика өлкәсендәге иң югары бүләк – Макс Планк медаленә лаек булды. Аны Немец физика җәмгыяте (DPG) бирә. Галим «астрофизика һәм космологиягә керткән өлеше» өчен бүләкләнде. Медаль аңа 2023 елның мартында Дрездендагы DPG еллык җыелышында рәсми рәвештә тапшырылачак.

Планк медале 1929 елда гамәлгә кертелгән, ә аның беренче лауреаты Альберт Эйнштейн булган.

«Ядкәр» шәҗәрә барлый

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе Гөлнара Габдрахманова Татарстан Дәүләт Советының 37 нче утырышында «Ядкәр» генеалогик порталы проекты турында сөйләде.

Ул соңгы берничә дистә елда Россиядә һәм дөньяда шәҗәрәләрне өйрәнүгә кызыксыну артканын билгеләп узды. Дәүләт архивына генеалогик мөрәҗәгатьләр саны артуы шул хакта сөйли. Шәҗәрәсен төзү үтенече белән еш кына танылган шәхесләр дә мөрәҗәгать итә. Мисал өчен, ул опера җырчысы Аида Гарифуллина гаиләсеннән шундый үтенеч килгәнен әйтте. Үз шәҗәрәсен төзү турында мөрәҗәгатьләр якын һәм ерак чит илләрдән дә килгән.

«Тулы бер авылның шәҗәрәсен төзү, бер яктан, нәтиҗәлерәк, икенче яктан, җиңелрәк. 50 йорт өчен проектның уртача бәясе 350 мең сум. Бер хуҗалыкта ике линияне дә эшлибез. Нәтиҗәдә, 100 шәҗәрә килеп чыга», – диде комитет рәисе.

Аның әйтүенчә, беренче этапта архив хезмәтенең генеалогик белгечләре авылларга чыга. Анда халык җыелышлары үткәреп, проект тәкъдим ителә һәм халык өчен анкеталаштыру, мәгълүмат туплау оештырыла. Аннары торак пункт буенча архив документлары, ревизия исемлекләре, метрика кенәгәләре барлана, иске татар теленнән тәрҗемә ителә һәм индексациялинә. Иң соңгы этапта бөтен тупланган мәгълүмат «Ядкәр» порталына кертелә, аннары авылның барлык халкының нәсел шәҗәрәсен төзү мөмкинлеге барлыкка килә. Иганәче һәм торак пункт халкы өчен презентация әзерләнә.

«Торак пунктларда мондый тикшеренүләр авыл турында кызыклы мәгълүматлар ачыкларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, никахлашучыларның иң яше һәм карты, авылның иң борынгы кешесе, үлем, аерылышу сәбәпләре турында кызыклы фактлар», – дип сөйләде Г. Габдрахманова.

Гөлнар ГАРИФУЛЛИНА.

«Безнең кавем» киңәя

Казан кооператив институтында Татар мәдәнияте үзәкләренең «Безнең кавем» III халыкара фестивале узды. «Фестивальгә йөзгә якын эш кабул иттек. Жюри дүрт номинация буенча килгән эшләрне карап, җиңүчеләрне билгеләде.

Барлыгы 80 авторга дипломнар тапшырылды. Эшләр Төркия, Эстония, Башкортстан, Оренбург, Самара өлкәләре, Пермь крае Барда районы, Новокузнецк, Нефтеюганск шәһәрләреннән, Татарстан районнары һәм Казан шәһәреннән килде», – диде институтның Дәрдмәнд ис. Татар мәдәнияте үзәге җитәкчесе Флюра Абдуллина.

«Максатыбыз – татар телен, гореф-гадәтләрне, милли ашларны, үрнәк булырдай сыйфатларыбызны түкми-чәчми яшь буынга тапшыру. Безнең үзәк тәҗрибә уртаклашырдай мәйдан булып тора», – дип саный Флюра Абдуллина.

«Фестивальдә катнашу ул – үз телебезгә хөрмәт, үз җирлегебездә яшәгән шәхесләрнең фикерен ишетү, өйрәнү, аңлау, гореф-гадәтебезне, милли ашларыбызны саклап калу теләге бар, дигәнне аңлата», – диде үз чыгышында кооператив институты ректоры Алсу Нәбиева.

Ф.Абдуллина хәбәр иткәнчә, фестивальгә килгән язмалар «Безнең кавем» китабына кертеләчәк.

«Һөнәр» фестиваленә кил!

5-11 декабрьдә Казаныбызда XIV «Һөнәр» Бөтенроссия яшь режиссура фестивале үтәчәк. Элек бу фестивальгә 35 яшькәчә режиссерларның спектакльләре сайлап алына торган булса, быел режиссерларның яшен 40 ка кадәр арттырганнар. Бу адым яшь режиссерларның күп булмавы, күбесенең исә кырык яшьләргә өлгереп җитүе белән аңлатыла.

Быел фестивальдә Владимир, Чиләбе һәм Санкт-Петербург театрларының спектакльләре күрсәтеләчәк.

Г.Кариев театрында Кол Гали буенча Р.Әюпов куйган «Йосыф» һәм Буада Н.Хәсәнов әсәре нигезендә Т.Кулов сәхнәләштергән «Дәрвиш» спектакльләре ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгына багышлап тәкъдим ителә.

Фестивальдә премьералар байтак. Г.Камал театрында А.Җаббаров куйган «Көл», режиссер С.Таһировский тинчуринлылар белән сәхнәләштергән «Хан кызы Турандык», әтнәлеләр һәм И.Казакбаевның уртак иҗат җимеше Ч.Айтматовның «Ак пароход»ы, Чаллы театрында А.Гыйләҗев әсәре буенча сәхнәләштерелгән «Болан» спектакльләре, мәсәлән, әле яңа гына сәхнә күрде.

«Һөнәр» фестивале быел Г.Кутуй әсәре буенча Т.Кулов куйган «Рөстәм маҗаралары» премьерасы белән ачылыр дип көтелә.

«Әкият» һәм Чаллы курчак театрлары спектакльләренең икесен – режиссер И.Зәйниев, берсен А.Гыймаев сәхнәләштергән. Рус яшь тамашачы театрының «Удивительный чердак» тамашасы өр-яңа булмаса да, карамый калганнарга күңелне җылыта торган, якты рухлы әсәр белән танышырга бер мөмкинлек. Г.Кариев театры артисты Булат Гатауллин татар әкияте нигезендә «Гөлчәчәк» исемле куркыныч тамаша куйган диләр һәм аны бөтен шартларын китереп кичке тугызда күрсәтәчәкләр. «Живой город» заманча сәнгатькә ярдәм фондының ике тамашасы да кемнәргәдер кызык булыр, бәлки.

Илгиз Зәйниев, Илсур Казакбаев, Айдар Җаббаров, Тимур Кулов, Резидә Гарипова – татарлардан яшь режиссерлар шуның белән вәссәлам, аларны да театр сөючеләр инде танып өлгерде. Яңа исемнәр юк дияргә була.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

1 нче биттә – Башкортстанның халык рәссамы Әдия Ситдыйкованың «Ана булу» картинасы.

Милли Шура: ҮЗГӘРЕШЛӘР һәм НИЯТЛӘР

Казанда XV «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы кысаларында Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура утырышы узды.

Әлеге чарада Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров Башкарма комитетның 2022 елдагы эшчәнлеге турында мәгълүмат бирде. Ул оешмадагы структур үзгәрешләр турында да аңлатты: «Бүгенге көндә Дини оешмалар эшен координацияләү өчен җаваплы хезмәткәр булып Баязит Зәйдуллин санала. Ә спорт юнәлешен Зөфәр Вәлиәхмәтов, төбәктәге массакүләм чаралар белән эшне Булат Ибраһим алып бара. Ул шулай ук алдынгы татар авылларының тормышын өйрәнеп, аларның уңай тәҗрибәсен тарату максатыннан Бөтендөнья татар конгрессы «Уңышка ирешкән татар авыллары» дигән проектны гамәлгә ашыра башлаганын әйтте. Илебезнең татар авылларының көнкүрешен өйрәнү юнәлешен журналист Рәшит Минһаҗев алып бара».

Утырышта беренче тапкыр Милли Шура бюросы барлыкка килде, комитетлар һәм бюро әгъзалары тәкъдим ителде. Бөтендөнья татар конгрессы рәисе Васил Шәйхразыев 75 әгъзаның 7 комитетка бүленәчәген әйтте.

Комитетлар:

• Милли мәгариф һәм фән (җитәкче – Дания Заһидуллина);

• Татар халкының мәдәнияте һәм рухи мирасы (җитәкче – Ркаил Зәйдуллин);

• Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм уртак татар мәгълүмат мохите (җитәкче – Илшат Әминов);

• Татарлар яшәгән төбәкләрдә эшмәкәрлекне үстерү һәм икътисади багланышларны булдыру (җитәкче – Ринат Насыйров);

• Татар дипломатиясе һәм халыкара элемтәләр, (җитәкче – Данис Шакиров);

• Татар дини оешмалар эшчәнлеген координацияләү төркеме (җитәкче – Рәфыйк Мөхәммәтшин);

• Татар тарихы һәм заман (җитәкче – Дамир Исхаков).

Васил Шәйхразыев әйтүенчә, һәр әгъза комитетка керү теләген үзе белдерә ала, комитет җитәкчесе чакыруы белән дә килергә мөмкин.

Комитет җитәкчеләре бюрога автомат рәвештә эләгә. Милли шура елына ике тапкыр җыелса, бюро елына ким дигәндә дүрт тапкыр җыелырга тиеш була.

Очрашуда Бөтендөнья татар конгрессының киләсе елга эш планы да ачыкланды. Өстәмәләр кертү өчен бер атна вакыт бирелде.

Милли шура утырышы барышында тарихчы Дамир Исхаков 2023 елны татар дөньясы өчен Дастаннар елы дип игълан итәргә иде дигән тәкъдим кертте.

«Дастаннарга тарихи аң салынган, аларны өйрәнергә кирәк, кызганыч, бездә кимчелекләр бар. Күрше халыкларда бу өлкәдә зур эш бара, бездә юк диярлек. Галимнәр эшли, әмма халыкка барып җитми. Бездә татар дөньясына сөйләрлек дастаннар бар», – диде ул.

Ркаил Зәйдулла фикеренчә, дастаннарга багышланган ел милли үзаңны үстерүдә зур роль уйный ала. Ул дастаннарны балаларга аңлатырга кирәк булуын ассызыклады: «Балаларга дастаннарны кабул итү, аңлау кыен. Балага яраклаштырып, дастанга нигезләнгән әсәрләр язу зарур. Аның мисаллары бар. Мәсәлән, азәрбайҗан язучысы Анарның борынгы дастанга нигезләнеп язган «Деде Коркут» дигән әсәре бар. Ул балалар өчен генә түгел, олылар өчен дә кызыклы. Дастаннарны олыларга да аңлатырга кирәк». Ул дастанга нигезләнеп язылган әсәрләр арасында бәйге уздырырга да тәкъдим итте.

Бөтендөнья татар конгрессы рәисе урынбасары Дания Заһидуллина да тәкъдимне хуплады. «Дастаннар тирән тарихи аңны саклый. Башка халыкларда дастаннар нигездә телдән телгә күчкән. Татар – китаплы халык. Шуңа күрә дастаннар китап форматына күчерелгән. Бу хакыйкатьне онытмасак иде», – диде ул.

Шәмсине котладылар

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында Татарстанның атказанган артисты Ренат Шәмсетдиновны илле яшьлек юбилее белән тәбрик иттеләр.

Сәнгать сөючеләр Р.Шәмсетдиновны күренекле артистларыбыз Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовларның кияве буларак белә. Күп еллар театрыбызга тугрылыклы хезмәт итеп, халык күңеленә кергән бу олпат гаиләнең вәкиле буларак, Ренат та сәхнәдә ышандыра торган халыкчан образлар иҗат итә, ана телебезнең сафлыгы сагында тора.

Көләч йөзле бу артистны режиссерлар да, тамашачы да бик ярата. Р.Вәлиев әсәре буенча куелган «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» спектаклендә Әфләтүн, шул ук авторның «И машина, машина...»сында Лемар, И.Юзеев, Ш.Мәҗитов әсәренә нигезләнеп сәхнәләштерелгән «Рәзидәкәй» тамашасында Габделхәй, М.Фәйзинең «Ак калфагы»нда Бакый, Г.Зәйнашева пьесасы буенча куелган «Гайфи бабай, өйлән давай!» спектаклендә Рөстәм һәм үзе кебек сөйкемле башка рольләре күп аның. Күптән түгел исә Р.Шәмсетдинов А.Гыйләҗевнең «Өч аршин җир»ендә Мирвәли, Г.Камалның «Беренче театр»ында Кәрим бай образларын гәүдәләндергәч, артистның классикага да теше үткәненә тагын бер кат инандык һәм бу спектакльләрне рәхәтләнеп тамаша кылдык.

Юбилей кичендә артистны Татарстан Мәдәният министрлыгының бүлек мөдире Айрат Фәйзрахманов тәбрикләп, хөкүмәт исеменнән рәхмәт хаты тапшырды. Казан шәһәре мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов Р.Шәмсетдиновның республикабыз тормышына керткән зур хезмәтен ассызыклап үтте. Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Әлкиләрнең Казандагы якташлык җәмгыяте рәисе Алсу Нәбиева район киявен аеруча җылы сүзләр белән телгә алды. Казан театр училищесындагы остазы – күренекле артистыбыз Илдар Хәйруллин, питрәчлеләр, авылдашы һәм туганы, Шәле егете, язучы Камил Кәримов, Татарстан Театр әһелләре берлегеннән Эльмира Фәтхуллина һәм театр артистлары юбилярга бәйрәмендә иң изге теләкләрен җиткерде. Чулпан Закирова җитәкчелегендәге «Казан» бию ансамбленең чыгышы кичәгә ямь өстәде.

Р.Шәмсетдиновның үзе өчен дә, тамашачы өчен дә иң зур бүләк бөтен котлаулардан соң уйналган «Алай түгел, болай ул» спектакле иде. Дүрт скетчтан торган гаҗәеп тормышчан, юмор белән сугарылган бу тамашада Ренат Лемар, Баһаветдин, Ата, Гарифҗан рольләрен башкарып, кич буе иҗат сөючеләренең күңелен рәхәтләндерде.

Вакыт уза, режиссерлар алмашына, әмма драматург Туфан Миңнуллинның тормышчан пьесалары, артист Ренат Шәмсетдиновның халыкчан иҗаты, сәхнә сөйкемлелеге һич искерми!

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Татар уеннары турында – төрек телендә



Төркиядә татар халык уеннарына багышланган фәнни китап чыкты. Аның авторы – Анкарадагы Хаҗи Бәйрәм Вәли исемендәге университет галиме Әркан Карагөз. Китап «Татар балалар уеннары» дип атала. Ул Евразия Язучылар берлегенең «Бәнгү» китап нәшриятында басылган.

Автор гыйльми әсәрендә уен сүзенең фәндә ничек аңлатылуын, АКШ, Европа, Төркия галимнәренең хезмәтләрен тикшергән. Уенның фольклор элементы гына булмыйча, аның фәлсәфә, социология, психология, педагогика, икътисад, коммуникация кебек тармакларны да кызыксындырган тема булуын искәрткән.

Ә.Карагөз татар телендәге уен белән бәйле сүзләр һәм сүзтезмәләрне барлаган, аларның тәрҗемәләрен биргән. Татар балалар уеннарын хәрәкәтле, драматик, җыр-биюле, зиһен сынаш кебек категорияләргә бүлеп тикшергән. Хәрәкәтле уеннарны 11 төргә бүлеп анализлаган.

Төрек галиме әсәрендә Нәкый Исәнбәт, Рәшит Ягъфәров, Кафия Закирова, Ләйлә Миңһаҗева, Фәрит Йосыпов, Гөлназ Йосыпова, Фәридә Хәмитова кебек татар галимнәренең хезмәтләрендә балалар уеннарының ничек тикшерелүен ачыклап үткән.

Китапта татар уеннарының исемнәре, терминнар һәм уеннарда кулланылган предметлар белән бәйле сүзлек тә тәкъдим ителгән.

Рушания АЛТАЙ.

● Федераль Иминлек Хезмәте мәгълүматлары буенча, июльдән сентябрьгә кадәр Россиядән 9,7 миллион кеше күченеп киткән, бу былтың икенче кварталындагыдан ике тапкырга диярлек күбрәк. Барлык китүчеләрнең 70 проценты биш илгә туры килә: Абхазия (2,5 млн), Төркия (2,1 млн), Казахстан (1,25 млн), Грузия (460 мең), Финляндия (430 мең).

● Apple кабат дөньяда иң кыйбатлы бренд дип танылган, ул 482,2 миллиард долларга бәяләнә. Иң кыйбатлы брендлар исемлегенә тагын Amazon, Microsoft, Google, Samsung, Toyota, Coca-Cola, Mercedes-Benz, Disney һәм Nike кертелгән.

● 2022 елда Россия олигархлары илдән 251 миллиард доллар акчаны чит илләргә чыгарган.

Ул – киләчәк шагыйре

(ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ РӨСТӘМ МИНГАЛИМНЕҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ)



Бөтен мәктәбебез белән Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Җәлил, Ф.Кәрим шигырьләрен ярыша-ярыша яттан сөйләгән, аларның каһарманнары белән әсәрләнеп йөргән чакларыбыз истән чыкмый... Алтмышынчы елларның җылымса җилләре тормышының бөтен авырлыгын үз җилкәләрендә татыган егет-җилкенчәкнең иҗади дәртен тагын да көчлерәк уяткан икән. Сугыш чоры балалары язган беренче әдәби әсәрләрнең үк һәркемне сискәндереп җибәрерлек тәэсирле булуының төп сәбәбе дә шундадыр..

Җитмешенче еллар башында яшь шагыйрь Рөстәм Мингалимовның «Эзләр» исемле беренче җыентыгы да нәкъ шундыйлардан иде. Бу җыентыкны бер тында укып чыктым да шагыйрьнең олылыгын акылым белән дә, күңелем белән дә тойдым. Шул сәгатьтән аның иҗатын үземә гомерлек юлдаш иттем. Үзе белән дә якыннан танышып, аның киңәшләре белән әдәби иҗатка кереп киттем. «Эзләр»дә сугыш ятимнәре, аның чордашларының коточкыч афәтләрдән сакланып калу өчен кылган гамәлләре, кичерешләре, газаплы хисләре язылган эзләр булып сурәтләнә. Кырыс реализм дип атала икән шундый сурәтләү ысулы.

«Эзләр» җыентыгындагы шигырьләре үз исеменнән: «Мин дөньяга килдем, минем үз дөньям, шигъри дөньям бар. Мин үз дөньям белән бөтен кешелекне яман чирләрдән, салкын җилләрдән, вәхшилектән саклаячакмын», – ди кебек. Шул фикерләрнең гомумиләштерелгән йомгагы булып «Кулым ныгысын әле», дигән шигырь тора. Юк, юк, кулы ныгыгач, дөньяның бар малын, мөлкәтен бармакларын батырып көрәп алырга хыялланмый ул. Аның ныклы кулы әнкәсен, гаиләсен, инде күргән-кичергән кимсетүләрдән аралап калу өчен дә, үз кавеме, милләтенең бу якты дөньядан бер эзсез югалмавы өчен дә кирәк. Ни кызганыч, тәкъдирендә газаплар кичәргә дучар ителгән ыру-кавемне көн саен кабатланып торган кырыслыклар сагалап тора шул. Кулы нык булса да, әткәсен сугышта һәлак булудан йолып кала алмый бала, ата-бабасы көн иткән туган авылы Йолдызны да саклап кала алмый шагыйрь. Иделне буып, электр станциясе төзелгәч, су астында калачак авыл күченеп тарала. Мондый язмышка милләтнең «тал бишеге» булган дистәләрчә, йөзләрчә татар авыллары дучар ителә.

Аэродром иде безнең урам –
Казлар күтәрелде каңгылдап.
Бүрәнәгә ут(ы)рып
уйлаштык та,
Мин китәргә булдым авылдан.
(«Авылдан хат»).

Шагыйрьнең тормыш юлын беләсең килсә, аның дүрт томлыкка тупланган иҗаты белән тулысынча танышып чыгарга кирәк. Кулы ныгыган саен, ул тагы да авыррак ташлар актара, иҗаты үскән саен, эзләре тирәнәя, адымнары киңәя.

Рөстәм Мингалимнең балалар өчен иҗат иткән шигырьләре, әкиятләре, пьесалары үз вакытында әдәбият белгечләренең игътибар үзәгендә булды, бүген дә аларга мөрәҗәгать итүчеләрнең кимегәне юк. Республикабыз мәктәпләрендә үзешчән театрлар аның «Шүрәлеләр үч алмый», «Сихерләнгән урман» кебек пьесаларын «сәхнәләштерүгә» алына. Аның әкият-пьесалары, чит телләргә тәрҗемә ителеп, курчак театрлары сәхнәсендә уйналды. Ә зурлар өчен язылган, җитди конфликтларга корылган пьесалары турында андый сүзне әйтеп булмый әлегә. Әйе, пьесаларның сыйфаты һичбер хилафсыз. Әнә К.Тинчурин театры (режиссёры – Р.Заһидуллин) «Өченче бүлмәдә эт яши»не сәхнәгә кабаттан кайтарды. Дәүләтнең бер кузәнәге булган гаиләнең, шул исәптән милли гаиләләрнең «төзеклеге», тулылыгы һәрчак актуаль булачак. «Кайда сез, ирләр?», «Кунак кызы гел килмәс» спектакльләре дә Әлмәт, Камал театрларында уңыш казанган иде. Ә менә «Тау артында илле бүре», «Дүрт кешелек урындык»ны нигәдер сәхнәләштерергә алынмыйлар. Юкса, бөтен дөньясы коррупциягә, ике төрле стандартларга корылган, кавемчелек биләп алган, базарлары ялган ризык, ялган дарулар белән тулган бүгенге заманда олы сәхнәне, олы экраннарны көтә бу пьесалар.

Р.Мингалим иҗатына әлегәчә тулы бәя бирелмәде, дип әйтү гадел булмас. Бәя бирүне, әдәбият белгечләре тарафыннан язылган фәнни мәкаләләр дәрәҗәсендә дөньяга чыгуны, әлбәттә, һәр иҗатчы көтеп яши. Әмма хак бәяне бары галиҗәнап вакыт үзе генә бирә ала. Күпсанлы укучылар, тамашачыларның бәясенә дә өметләнә иҗатчы. Ни дисәң дә, ул үзенең әсәрләрен, әдәбият, сәнгать белгече ничек бәяләр, дип түгел, ә укучыларына юллап игът итә ич. Әйе, бу хакта сүз куертасы юк. Әдәбият, сәнгать белгече дә шул ук укучы, тамашачы бит инде. Укучылар арасында танылу өчен трибуна булырга, радио-телевидение аша чыгышлар ясарга кирәгеген дә белеп тора иҗатчы. Экраннарга, радио эфирына чыгарга һәрчак әзер иде Рөстәм абый. Үз иҗаты белән дә, бигрәк тә үзе табып-барлап торган шәкертләрен дөньяга чыгару теләге белән дә... Алабугада яшәп иҗат итүче, сукыр шагыйрь Фазыл Шәехнең моңарчы беркем дә күрмәгән, ишетмәгән шигырьләрен үзе туплап, редакцияләргә илтеп бастырды. Үзе үк, артыннан йөреп, китап нәшриятында җыентык бастырып чыгарды. Аның «Көзге күкрәү» исемле тәүге китабын Татарстан радиосы аша үзе һәм артистлар укуында халыкка җиткерде.

Актаныштa «Агыйдел дулкыннары» иҗатчыларының, барлыгы 25 кешенең, иҗат үрнәкләрен Татарстан китап нәшриятында бастырып чыгаргач та нәкъ шулай булды. Язучылар берлегенең 70-80 нче елларда идарә әгъзалары, бигрәк тә әдәби киңәшчеләре яшь иҗатчыларны барлау, остазлык итүне изге бурычлары дип күрә иде. Таңнан торып озын юлга чыгып китә идем. Казанга иртәнге сәгать 7дә барып җитү белән, Язучылар йортының икенче катындагы кырый бүлмәгә үтеп керүгә, күзлеген текә маңгаена күтәреп, Рөстәм абый торып басар иде дә:

– Килеп җиттеңме, дустым? Тагы ниләр язып алып килдең? – дияр иде.

Эш күплектән сөенә иде. Чип-чиста иҗат үрнәкләрен үзе үк бүлмәсенә кергән бер язучыга кычкырып укыр иде, үзен бик бәхетле санар иде. Миңа карата аеруча игътибарлы булды. Моңа үземнең дә аның иҗатын үрнәк итеп, шигырьләрен күп еллар сәхнәдән сөйләвем тәэсир иткәндер, бәлки. «Иртәгә» исемле поэмасын тулы килеш яттан сәхнәдән сөйләвемне үзе дә тыңлап, берчак: «Кара әле, әйбәт кенә язабыз икән бит!» – дип куйган иде.

– Бик әйбәт язасыз, Рөстәм абый, тамашачылар күп тә бит, укучылар азайганнан-азая, – дим аңа.

– Димәк, тамаша кирәк халыкка, сәхнәдән укыганны тыңларга.

Әйе, Рөстәм абыйның иҗаты кабат сәхнәгә кайтты. Аның балалар өчен язылган пьесалары мәктәп, курчак театрлары сәхнәсеннән төшкәне дә юк. Менә көтмәгәндә-уйламаганда, шагыйрьнең моннан 40-50 ел элек язган шигырьләрен Дәүләт фольклор ансамбле репертуарына керттеләр. Ансамбльнең һәм филармониянең сәнгать җитәкчесе, чын-чынлап зыялы иҗатчыбыз Айдар Фәйзрахманов аның фәлсәфи шигырьләреннән менә дигән композиция төзеп, «музыкаль-әдәби театр» оештырган. «Олы юл әйтте» беренче карашка фәкать мәхәббәт шигыре кебек, ә чынында – татар халкының мең еллык дәүләтчелеге тарихы турында шагыйрьнең уйланулары бар анда. Нинди моңлы көйләр, җырлар белән урап алган аны Айдар. Ул шагыйрьнең иҗатын тулысынча белә инде. Күрәсең, аңа да, «Иртәгә» поэмасындагы «Халкы булгач, аның инде юлы булырга тиеш», дигән юллары нык тәэсир иткәндер. «Иртәгә» поэмасы – шагыйрьнең иң югары биеклеге. Ул туксанынчы еллардагы яңарышларны дистә еллар алдан ук күрә. Әйе, «Кулым нысын әле» дигән яшүсмер шагыйрь, үз иҗатының биеклегенә күтәрелгәч, туган халкына, милләткә нәкъ Тукайча: «Безгә музейга иртәрәк, музей ул үле кораллар өчен. Без бит әле тере. Безгә заман тизлегеннән калмас өчен үрә торып баскан ат кебек ярсу, гайрәтле, көчле булырга кирәк», – дип чакыра. Олы юл монологын тыныч кына, пышылдап кына укый А. Фәйзрахманов. Әмма ул пышылдауда күпме кысылган энергия, тартылган җәя киеренкелеге, уй-фикерләрнең тыгызлыгы бар.

Поэмалар турында сүз чыккач, аның әлегрәк иҗат ителгән «Минем дәүләтем», «Күз карасы» поэмалары да «Иртәгә»гә аваздаш икәнлеген, аңа килү адымнары буларак кабул ителүен таныйрбыз... Ил-көн сәхнәсеннән совет идеологиясенең сәясәте төшкән чорларда күп кенә шагыйрьләрнең «кызыл» шигырьләрен «эзле» башлаучылар күбәйде. Р.Мингалимнең: «Бигрәк каты кыздырасың, кояш, әллә син дә коммунистмы?» дигәнрәк шигъри юлларына кызыл чүпрәк эләргә теләүчеләр дә табыла. Әмма ул чүпрәк анда ятмады. Чөнки Рөстәм абыйның әлеге шигъри юллары дәүләт идеологиясен йөгәнләгән партиядән каһкаһәләп көлүе икәнен аңлаучылар күбрәк иде. «КамАЗ» удар төзелешенә багышлап язылган «Күз карасын» да кызарта алмадылар. Чөнки Рөстәм абый «Кулларым нысын әле», дип язганчы ук, кечкенә генә гәүдәсенә, арык иңнәренә авыр капчыклар күтәреп вокзалларда йөкче булып эшләгән, Казахстан далаларында чирәм җир күтәреп, тир түккән ир-егет иде. Ул ил төзелешендә барган һәр яңалыкны кол көненә төшкән халыкны авыр кул хезмәтеннән арындыру, гади халыкның тормышын яхшырту чарасы булмасмы дип кабул итә иде. Хезмәтнең яшәү чыганагы, хезмәтсез алгарыш булмавын коммунистлар идеологиясеннән түгел, ә әнкәсе вәгазьләреннән, үзе тапкан хәләл тәгамне татыганнан чыгып белә иде.

Р.Мингалим остаз буларак беркайчан да үз шигырьләрен мисалга китерми. И.Юзеев, Ә.Давыдов, С.Хәким, Г.Афзал, Х.Туфаннарның, үз замандашларының иҗатларын үрнәк сыйфатында тәкъдим итә иде. «Иҗатчының иң олы миссиясе хаклыкны, фәкать дөреслекне язу. Шигырьләр хис белән языла, әмма аларда акыл югалмасын. Моның өчен иҗатчылар бер-берсе белән иҗади хезмәттәшлектә булырга, бер-берсенә ихластан игътибарлы булырга тиеш. Мин үзем язганнарны Әнвәр абый Давыдовка укып күрсәтмичә бастырырга бирмәдем, ә Илдар Юзеев белән бер-беребезгә укымыйча бер генә шигырьне дә, хәтта балалар өчен язган шигырьләребезне дә бастырмыйбыз», – дия иде. Шуңадыр да аның иң әүвәл иҗатташлары алдында абруе зур, дуслары ихлас булды, дип беләм.

Иҗат кешесенең тормыш коллизияләре катлаулырак. Туа-тумышка ятимлек ачысын татыган Ир-Ата, кызлары Айсылу белән Алсуның үзенә охшап талантлы булуларына, музыкада, әдәби иҗатта, рәсем сәнгатендә зур биеклекләр яуларга сәләтле булуларына куанып, гомере буена аларга ярдәм итәргә тырышты. Көтмәгәндә-уйламаганда хасил булган каты авыру да аны ул омтылышларыннан, теләкләреннән чигендермәде. Дистә елга сузылган авыру аны олы иҗатыннан аера алмады. Шулай яшәде, шулай иҗат итте. Вакыт үткән саен, гел яңача ачыла барачак иҗатына һәрчак ихтыяҗ туып торачак. Халык шагыйре булып, киләчәк шагыйре булып китте ул безнең арабыздан.

Мөхәммәт МИРЗА.

(Дәвамы. Башы 45 нче санда).

1816 елда үткәрелгән җанисәп Бүләр волосте авылларында гомер итүче ир-атлар санын менә болай тасвирлый:

№1-6 авыллар – старшина Айчүәк Нигъмәтуллин, №7-13 – Әхтәм Җомангулов, №14-29 – Габделвахит Ибраһимов, №30-49 – капитан Баязит Султанов командалыгында була. (НА РБ. Ф. И-138. Оп. 2. Д. 151, 1024-1032 бб; Д. 154, 482-492 бб.

№	Деревни	Башкирское сословие	Тептярское сословие	Ясачные татары	Мещер. сословие
1	Иркеняш	58	1	-	-
2	Чуплюково	40	50	-	-
3	Сасыбрун	106	-	-	-
4	Семяково	48	30	4	-
5	Мушуга	124	8	-	-
6	Атрякле	132	11	-	-
7	Исансупово	3	167	-	-
8	Кулуново	34	35	-	1
9	Качкиново	31	39	-	-
10	Тюково	19	91	-	-
11	Усы	105	96	-	-
12	Зюбеирово	120	-	-	-
13	Айманово	196	-	-	-
14	Чуракаево	72	-	-	-
15	Зиланово	70	-	-	-
16	Агбязово	56	-	-	-
17	Альметево	44	-	-	-
18	Амекеево	88	126	-	-
19	Карамалы	30	7	13	-
20	Тлянчино	8	84	-	-
21	Кубяково	32	33	-	-
22	Бекабызово	27	55	-	-
22	Буляково	49	-	-	-
23	Уразметево	60	129	-	-
24	Суекеево	46	5	4	-
25	Масягутово	15	-	-	-
26	Буляр	15	64	14	-
27	Сеитово	94	34	-	-
28	Сикия	94	-	-	-
29	Табанликул	42	-	-	4
30	Байсарово	200	69	-	-
31	Якшиево	56	9	-	-
32	Аккузево	80	15	-	-
33	Ахуново	12	29	-	-
34	Минляр	8	125	1	-
35	Бишкумачево	6	82	-	-
36	Улыимен	106	17	-	-
37	Саперово	146	2	-	-
38	Асылтуш на речке Шабыз, называемой Челмонарат	-	6	-	-
39	Токмак	81	18	-	-
40	Старый Буляр	-	102	-	-
41	Калтаково	-	120	-	-
42	Чупаево	-	56	-	-
43	Ятово	-	22	-	-
44	Шайчурино	-	122	-	-
45	Поисево	-	272	-	-
46	Илтимерово	-	67	-	-
47	Аняково	-	105	-	-
48	Тыгырмен	-	22	-	-
49	Казгалак-Яхшеево	-	7	-	-
50	Апасево	55	-	52	-
51	Каинтюба	7	80	-	-
52	Бексентеево	79	47	-	1
53	Курмашево	89	129	-	-
54	Челмонарат	184	-	-	-

Вахит ИМАМОВ

ТАТАР КЕМНЕ БАЕТА?

1834 елгы җанисәп вакытында Минзәлә өязенең Бүләр волостендагы 27 авылда йөзәрләгән татар ирләре үзләрен «башкорт» – җир хуҗасы дип тоеп яши:

Чуракай авылында – 90 ир-ат; Сәфәрдә – 195; Ахунда 11; Аккүздә – 81; Меңнәрдә – 8; Байсарда – 35; Еланда – 86; Әгъбәстә – 77; Әлмәттә – 61; Сөяккәйдә – 28; Бәкәбездә – 39; Теләнчедә – 11; Күбәктә – 63; Карамалыда – 45; Табанлыкүлдә – 60; Бүләктә – 69; Сәеттә – 79; Тат.Бүләрдә – 3; Сикияда – 81; Югары һәм Түбән Яхшыйда – 66; Олы Имәндә – 27; Уразмәттә – 86; Чалманаратта – 35; Бишкүмәчтә – 1; Мәсәгуттә – 25; Мәчтидә – 43 ир-ат.

Халык тагын 20 елдан соң нинди хәвеф туасын чамаламый әле. 1840 елларда Казахстанны да аяк астына сузып салганнан соң, чик буен саклауның һич кирәге калмый. 1848 елда ук 50 ел буе яшәп килгән Башкорт-мишәр гаскәре икегә бүленә. 200 мең ир-атны хәрби хезмәткә чакыру урынына акчалата салым түләргә мәҗбүр итәләр. 100 мең ир-ат кына хәрби төзелеш яки хәрби ихтыяҗ туган очрак өчен дип исәптә калдырыла. 1855 елда «Башкорт гаскәрен өр-яңача туплыйбыз» дигән сәбәп уйлап табалар. Бу яңа гаскәргә башкорт белән мишәрләрдән тыш, типтәр белән бобыль-ялгызак катлам ирләре дә керергә тиеш була. «Яңа» «башкорт» гаскәрен туплау өчен Оренбург губернасын 28 кантон һәм 394 йорт-түбәгә бүлеп чыгалар. 13 «башкорт» һәм 4 «мишәр» кантоны, бер полк ир җыеп, аларны «хәрби хезмәт»кә озатырга тиеш була. Һәм инде 1840 еллар ахырында ук башкорт белән мишәр ирләренең 14 проценты төрле линияләрдә хезмәт итә башлый. Аларның бер өлеше Югары Җаек – Стәрлетамак сәүдә трактын төзүгә тартыла, икенче командалар Орск-Троицк калалары арасындагы чик буена сакка озатыла. Шул ук хәрби хезмәткә дип чакырылган ирләр урман кисү һәм утын әзерләү, шәһәр урамнарын чистарту һәм төзекләндерү, почта эшен тәэмин итү, юллар һәм күперләрне төзәтү, тагын әллә никадәр «ил бурычы»н үтәүгә җигелә. 1855 елда типтәр катламын да «Башкорт гаскәре» составына бәйләп куялар, әмма хәзер инде аңа тартылган барча ир-ат «башкорт» дип кенә аталырга тиеш була. Халык, ялгыш, читкә чыгып качу җаен эзләмәсен өчен, Уфа провинциясендә үзең теләгән җиргә күчеп утыру тыела, өяздән-өязгә яки губерна буйлап хәрәкәт иткәндә, заставалар аша паспорт күрсәтеп кенә узарга ярый. 1863 елда кантоннар санын, эреләндереп, 11 гә генә калдыралар. Ул кантон чикләре бүгенге өяз контурларын хәтерләтә. Ә 1865 елда «башкортлар белән идарә итүне» гражданлык оешмаларына тапшыралар да, «Башкорт гаскәре» тулысынча юкка чыгарыла. 1865 елда мөстәкыйль Уфа губернасы барлыкка килә һәм Уфа, Бөре, Бәләбәй, Минзәлә, Стәрлетамак, Троицк, Златоуст өязләре аның составына кертелә.

Гаскәрдәге барлык мишәр, типтәр катламнарын юкка чыгарып, аларны «башкорт» кына дип атый башлау 1859 елда үткәрелгән җанисәп вакытында ук үзен нык сиздерә. Бүген Илеш районы составында яшәүче Кадер авылындагы типтәрләрнең барчасы да (26 гаилә), элек ясаклы татар катламында саналган янә 7 гаилә, 1855 ел указы нигезендә, шундук «башкорт»лар катламына күчерелә. Илеш районындагы Сеңгерән белән Актаныштагы Чынык, Адай, Карач, Усы, Буранчы авылларындагы татар крестьяннарына 1863 елда 10 ар дисәтинә генә җир бүлеп бирелә, сәбәбе – «башкорт»ка әверелгән авылдашларына 40 ар дисәтинә бүлү өчен, чәчүлек җирләрне «үз авызларыннан өзеп бирергә» тиеш булалар.

1855 елдан соң Минзәлә өязендә урнашкан 18 нче «башкорт» кантонына күз йөгертик. Аның 1 нче йортын Бүләр волостеның Байсар авылы тәшкил итә, йорт старшинасы – урядник Шаһисолтан Солтанов.

1859 елгы җанисәп вакытында Байсарда 663 ир-ат белән 662 хатын-кыз исәпкә алына. Авылдагы 21 хуҗалык кына Бүләр волостеның «асаба башкорты» булып исәпләнә, ә «башкорт» катламына язылган 164 татар гаиләсе – 1713, 1738 елларда ук Йәнәй волостеның Тугызбуй түбәсеннән күчеп утыра. Алардан тыш, авылда тагын типтәр булып санала торган 61 хуҗалык бар. Әгәр авылдагы типтәрләр дә 1855 ел указы нигезендә «башкорт» катламына күчсә, һәрбер ир-ат өчен 40 ар дисәтинә җирне каян эзләп табасы? Ничек җан асрарга? Башка бер төрле дә чара таба алмагач, Байсар авылының бер төркем ирләре Сөн елгасы ярында Яңа Байсар дигән тагын бер авыл, ә икенче зур төркем Яңавыл районы белән Пермь өлкәсе чигендәге Биз елгасы буенда өченче Байсар авылын нигезләргә мәҗбүр була. Ә төп авылның үзендә 1870 елгы җанисәптә 419 ир-ат белән 388 хатын-кыз гына яшәп калган булуы ачыклана.

Менә шулай итеп дистә еллар буена ипле генә яшәп килгән уклад җимерелә башлый. Элек «җир волосте» дип аталган термин үзе үк, менә шушы указлар нәтиҗәсендә, барча Уфа губернасы буйлап милли төсмер ала. Бүген Илеш районында, элек Бүләр волосте составында булган Исәмәт авылы 1859 елгы җанисәп вакытында 236 «башкорт» татарыннан, 136 типтәр һәм 35 мишәрдән торган булса, хәзер аларның ким дигәндә 80 процентын «башкорт» дип язалар.

Гасырлар буе бер-берсенә ут күрше булып, ярдәмләшеп, өстәвенә әле кияү-киленнәр дә алмашып яшәгән татар-башкорт халыкларының бердәмлеге һәм һаман саен туганлаша баруы патша хөкүмәтенең үтенә тими калмый. Патшабикә Анна Иоанновна 1736 елның 19 февраль указы белән татар белән башкорт вәкилләре арасында никахлашуны тыю, ә татар муллаларын, гомумән, Уфа провинциясеннән куып чыгару белән янаса да, хөкүмәтнең бу явыз нияте барып чыкмый. Көчләп чукындырганнан соң, кабат ислам диненә кайткан өчен, Кисәбикә Бәйрасова атлы хатынны 1739 елда Екатеринбург каласының үзәк мәйданында яндырып үтерсәләр дә, мондый коточкыч вәхшилек тә татар-башкорт өчен сабак булмый, алар үз мәчетләренә йөрүне һәм Аллаһ Тәгаләгә табынуны дәвам итә.

Менә хәзер, 1855 елда барча татар-типтәр-мишәрне йотарга тиешле бердәм «Башкорт гаскәре» булдыруны уйлап тапкач та, явыз патша хөкүмәте татар халкын элеккечә үк юкка чыгаруны максат итеп куя. Нәкъ шушы «Башкорт гаскәре» турындагы фәрманнан соң татарларны башкорт арасына күчереп эретү яки башкортлаштыру, ә Минзәлә яки Бәләбәй, Бөре өязләрендәге татарларны көчләп чукындыру, христиан диненә керүдән баш тартсалар, Себергә сөрү, солдатка җибәрү кебек пычрак адымнар кылудан да тукталып калмыйлар. Һәр сүз дәлил сорый, шуңа күчик.

Элек Бүләр олысында исәпләнгән Олы Имән авылында 1859 елда 111 хуҗалыкта 312 ир-ат һәм 292 хатын-кыз гомер сөргән була. Авыл тулысынча татарлардан гына торса да, хуҗалыкларның 20 се – Бүләр олысы, 84 хуҗалык – Йәнәй, 7 хуҗалык Байлар олысына карый. Шушы кадәр халык арасыннан нindидер юл белән сайлап, яки белми-абаламый кылган бер җинаяте өчен, Мөхәммәтша Шәмсетдиновны 1860 елда чукынырга мәҗбүр итәләр һәм ул Чиләбе каласына күчерелә. Ә 1857 елда кылган нindидер саксыз адымы яисә чукындырудан тулысынча баш тартканы өчен, Игътисам Шәрипов Себергә сөрелә.

Әмәкәй авылыннан Миңлегол Мансуров 1856 елда – Себергә, бер елдан соң Габдерәфыйк Габделхаков каторга эшләренә озатыла.

(Дәвамы киләсе санда).

Китәр чакны сизгәнгәме, Бераз гына ямансу...

Танылга шагыйрь һәм прозаик Хәйдәрнең (Хәйдәр Гайнетдинов) туууына 70 ел

ХӘЙДӘР

АВЫРЫП ЯТКАНДА

Сәләмәгә төренеп китеп барды
шатлыкларым җилләр уңаена.
Алгысынмас инде дигән идем,
йөрәк типми әле үз җаена.

Кай тарафтан исә җилләр бүген,–
үтеп-сүтеп йөри тәрәз шакып.
Сак кылансын иде, беләдер бит –
тәрәзәләр минем күптән ватык.

Тышта хәзер язмы, көзме икән,
яңгырмы ул коя шыбырдатып?
Ә бүлмәгә тулган караңгылык,
иртәме бу, кичме – кайсы вакыт?

Кайсы фасыл икән табигатьтә,–
уйлап тап син менә кырын ятып.
Акылыннан язган билгесезлек
кысып ала шулай чытырдатып.

Табигать тә бәлки аңламыйдыр –
Кешелектә хәзер кайсы вакыт?
...Өй түрендә миләш, сорау кебек,
әкрен генә тора тәрәз шакып.

* * *

Сызылып керде җанга карурманның
ераклардан килгән шаулары.
Шуны гына көтеп торган гүя –
тынгысыз җан кушылып шаулады.

Шаулады ул.
Бөтен уй-фикерләр
әверелде көчле шау-шуга.
Нигә әле һәрбер күренешне
кабатларга шулай ашыгам?!

Тамчы булып тамам – яңгыр яуса,
чәчәк атам кинәт болында.
Узган юллар күмелеп кала алмый –
маңгаема сызыла, кулыма.

Тиешмени кеше, шатлык килсә,
гел елмаеп кына йөрергә,
кайгы-хәсрәт ишелеп төшсә әгәр,
күз яшенә әйләндерергә?..

Күңелләргә керсен шау-шулары,–
урман мине шундый сагынган.
Шаулый-шаулый шулай җырлар туар
һәм яңгырар моңлы «Карурман».

ГОМЕР ЮРАУ

Урманнарга керсәм, җырлар сузам,
сайрар кошлар җырны тыңласын.
Санамасын кәккүк елларымны,
онытсын ул бөтен дөньясын!

Каян белсен кәккүк хыялымны –
ул бары тик бер ел юрады.
Бер авазын мең кат яңгыратты
туган якның якты урманы!

* * *

Дусларга

Ни генә күрсәк тә,
юрамыйк яманга.
Лаеклы булыйк без
бу якты заманга.

Юрамыйк язмышка
бәхетсез киләчәк –
болытлы көннәр дә
яшенләп көләчәк.

Табигать кызганмый
биргән бит моңнарны –
ачып сал күңелеңне,
тылсымла дөньяны.

Яшикче риясыз.
Олы җан каршында
йөрәккә әйләнер
мең еллык ташың да!

ИДЕЛ

I
(уй килә)

Аягүрә баса Идел,
агарынган дулкыннары,–
Идел-суга аккан, ахры,
бабамнарның кайнар каны.

II
(иске Казан)

Чаңы белән чиркәү
күккә кереп баткан.
Мәчетләре тора
киенгән дә актан.

Халкым өчен монда
хәләл таңнар аткан,
җылы җилләр искән
бары кыйбла яктан.

Мәчетләре тора
киенгән дә актан.
Сөембикә сөйли
ил тарихын яттан.

III
(яңа Казан)

Сөембикә сөйли
ил тарихын яттан.
Ае гына аның
инде күккә ашкан.

Төннәре дә балкый,
чагылдыра нуры.
Урамнарга тулган
моңлы татар җыры.

IV
Ага Идел.
Күкрәгендә аның
йөрәк булып ап-ак кояш ята.
Идел безне нәкъ мәҗүси иткән,
табындырган менә шушы якка.

Ятратканбыз Идел-Әтилне без.
Газиз халкым борын-борынгыдан
суларның да эчкән кояшлысын.
Без, мөгаен, Кояш ыруыннан!

V
Аягүрә баса Идел
һәм түгелә күңеленә.
Табындырырга тели ул
һәр кешене Ил-җиренә.

Күренмиләр – кар-буранга
түзалмыйча
җылы якка очкан бугай
оялар да...

Кайтыр алар язлар җиткәч –
сау булсыннар.
Нәрсә бар соң кыйммәтрәк
сау булудан?!
Каршы алырга кошларны
бергә-бергә
ак кар ерып язга киттек
туры юлдан.

* * *

Мөдәррис Әгъләмовка

Әйтерсең лә җирдә кыш булмаган,
әйтерсең лә җирдә яз гына.
...Очраштырды безне Аккош күле.
– Языламы шигырь?
– Языла!

БЫЕЛ

Урманнарда йөри көз рухы,
килеп чыга тып-тын аланнарга;
әкрен генә килеп пышылдый да
якты көлү кала чаганнарда.

Көзге урман көлә яна-яна!
Уйламый да җирдә салкын барын.
Хәтерләми бугай аланнары
ап-ак көртләр күмеп киткән чагын.

Кошлар инде оча җылы якка.
Ә яфраклар ничек торсын чыдап:
иярергә теләп талпына да
ут бураны булып кала уйнап...

Котыбыңны хәтта эретер төсле,
ут бураны булып уйный урман!
...Гамьсез генә йөрим аланнарда,
салкын кышлар быел килмәс сыман.

* * *

Аксакаллар

Олыгая дөньялар да...
Кояшлы көзге басу.
Бер яшел чагы узса,
табигать тә ямансу.

Өметләнмим яшәренү
яшьләргә килгән яздан.
Кемгә дә китәр алдыннан
хәтерләп йөрү язган.

Бар да кала яңаларга:
йолдызлар һәм аебыз.
Гомер чыгышыннан идек,
шунда кайтып баербыз.

Чал чәчләрдән күчәр безнең
ап-ак төс каеннарга,–
үч тотмадык дөньялыкка,
башларда кайгы барга.

Исән-имин кала бар да,
кояшлы көзге басу.
Китәр чакны сизгәнгәме,
бераз гына ямансу.

* * *

Хәерле юл теләп калдык
куллар болгап,
тезелешеп кошлар китте
җылы якка.
Яшел язга туганнарча
сәламнәрен
җибәрә көз кош кәрваны –
очар хатта.

Агач башларында калды
оялары,
калган иде камышлыкта,
кыяларда.

Хәл сораштык шулай.
Мондый язда
тән языла, җаннар языла.
Рәхәтләнеп китә җаның-тәнең,
җан язылса, шигырь языла.

Сакла менә шушы рухыңны,
куырылып төшмә салкында.
Сусәрттеләр көрәш дәртле сүзне:
Салкында да ян син ялкында!

Кайта әнә яңа мәгънә алып
шушы сүзләр шагыйрь телендә:
– Ялкында шул минем йөрәгем дә,
Ялкында шул минем телем дә...

Кычкырулар була вакытлыча,
булыр инде, булыр аз гына...
Үз сүзендә торыр шагыйрьләр бар:
– Куырылмый шигырь,
языла!

* * *

Үз гомерендә бу дөньяның
табалмаган ямьнәрен
уйлап карарга булса да
хакы бардыр бәндәнең!

Тургай моңы юды күңелемне
агарганчы.
Әйтмәсеннәр: гел сагыштан
яралгандыр бу бала...
Әй, җырладым,
онытылдым бер мизгелгә...

Хәтеремнән алга күчте учаклар,
тагын бер кат янарга вәгъдә итеп.
Юл чатында көтеп торыр үсмер кыз
гомеремнең шул турына җитүен.

Учларыма кысып шәфәкъ нурларын
төнге урманнан кешеләргә йөгердем.
Эзләп таптым көлеп торган әнкәйне,
кочакладым күзеннән яшь тамганчы.

Тургай моңы юды күңелемне
сабыйланганчы!

Теләп алган бәхет һәм фаҗига

Данга күмелеп яшәгән, әмма ялгызлыкта вафат булган сәхнә йолдызы, татар халкының беренче актрисасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның тууына 130 ел.

«Туташ» документаль романының авторы Айгөл Әхмәтгалиева белән әңгәмә

– Айгөл ханым, актрисаның тормышын өйрәнгәндә иң тетрәндергече ни иде?

– Аның тормышын ике ел өйрәндем, 2019 елда «Туташ» китабы дөнья күрде. Аңа кадәр Сәхипҗамалны беренче татар артисткасы буларак һәм төрле шәһәрләрдә театр труппалары ачуы турында гына белә идем. Галимнәр һәм язучыларның аның турында документаль язмалары бар, шөкер. Әмма аның биографиясендә ак таплар, ачыкланмаган фактлар шактый. Кайда, кайчан туган – бернинди дә документ юк диярлек. Без аның май аенда туганын да белмибез. Тукай аңа энҗе чәчәкләрен нәкъ туган көненә бүләк иткәне билгеле. Туган елы белән дә шул ук мәрәкә. Үз көндәлекләрендә туган елын өч дәфтәрдә өч төрле итеп күрсәткән. Ул этисен Яшел Үзәннең Әрә авылыннан дип яза. Казан, Уфа, Ижау архивларында, бу авылда аның этисенә кагылышлы бер генә документ та табылмады. Ул үзен ярлы гаиләдән дип тасвирлый, әмма бу да бер хәйлә була ала. Затлы мулла нәселеннән булучыларның күбесе, совет сәясәтен аңлап, үзләрен ярлы крестьян гаиләсеннән дип сөйләргә мәҗбүр булган. Сәхипҗамалның ярлы гаиләдә тууына ышану читен, чөнки ул башта мәдрәсәдә дини белем ала, аннары Маһруй Мозаффария укыткан кызлар өчен урыс-татар мәктәбендә укый. Бу – элита мәктәбе. Өстәвенә, бал биюләре мәктәбенә йөри. Анда уку чыгымнар таләп иткән. Шуңа да аның үзен ярлы гаиләдә тудым дип тасвирлавы ул чордагы язылмаган кануннарга буйсынудан тугандыр.

Ижау архивында ире белән никахлашу документы табылды. Анда актрисаның туган җире итеп Чуашстанның Козловский районы Әлмән авылы язылган. Соңрак архивта этисе Гыйззәтулла Хәмидуллинның документлары да нәкъ шунда туганлыгын раслады. Этисенең бертуган абыйлары турында да мәгълүматлар бар. Димәк, Волжскаяның нәсел тамыры – Әлмән авылыннан.

Ул әни булу бәхетенә ирешә алмый. Бик күп эшләү, гастрольләрдә ачлы-туклы йөрүләр аркасында аның саулыгы тәмам туза. Үпкәсе белән дә, ашказаны белән дә проблемалары була. Сәхнәдә эшләү бәрабәренә ул әни булу бәхетеннән мәхрүм кала.

– Бәлки, сез үзегезнең күзлектән чыгып, мондый нәтиҗә ясыйсыздыр, кемдер гаилә, бала табуны бәхет дип санамаска да мөмкин.

– Бу фараз түгел. Актриса Ижауда яшәгәндә аның янына язучы Гази Кашшаф килә һәм аның белән әңгәмәдә Сәхипҗамал бу темага да кагыла. «Кызганыч, бер бала алып кайткан идек, ул кайту белән үлде», – ди. Авыру булу сәбәпле мин бала таба алмадым, дигән истәлекләре дә бар. Сәхнәне өстен кую гына булмаган, ана бәхетен татый алмавына үкенү хисләре кичерә. Шулай да алар ире белән олыгайгач тәрбиягә бала алып кайта. Сугыштан соң Ижауда «балалар йортын ябабыз, балаларны таратабыз», – дигән хәбәр чыккач, актриса ире белән үзләренә асрамага мәктәп укучысы яшендә бер кызны сайлаган. Аның бертуган энесеме, абыйсымы да булган. Балалар йорты мөдире икесен дә алырга, аермаска сорый, әмма актриса кыз бала гына кирәк, дип кырт кисә. Ул кызның исемен кемдер Неля ди, кемдер Сәхипҗамалның аңа Асия дип дәшкәнен әйтә. Күршеләре актриса һәр иртәне ул баланың чәчләрен үреп, тасмалар тагып мәктәпкә үзе озатты, көн саен каршы алды, дип искә ала. Шулай да ул кызга кырысрак булды диләр, артык чәпчемәгән, назламыйча, кочакламыйча, үзенчә яраткан. Ә ире Владимир Русинов аны үз баласы кебек яратты, диләр. Кыз баланың язмышы билгесез, медицина институтын бетергәч, Яңа Чабаксар шәһәренә эшкә киткән. Һөнәре – табиб. Мин аны да эзләдем, ләкин таба алмадым. Баштагы мәлдә картлар йортына эләккән Сәхипҗамалны асрамага алган кызы килеп йөргән дип әйттеләр, аннары юк булган. Ни өчен янәшәсендә калмаган дигән сорауларга җавап юк.

– Яшүсмер кызга сәхнәгә чыгарга Фатих Әмирхан тәкъдим итә. Бу татар дөньясында бомба шартлауга тиң була. Йөзе капланмаган килеш ирләр рәтендә бар кеше хозурына чыгу – ул вакытта башка сыймаслык гамәл. Ни өчен нәкъ менә Сәхипҗамал?

– Сәхипҗамалның таланты, даны, һөнәре – Аллаһ биргән, шул ук вакытта үзе теләп алган бәхете һәм фаҗигасе дә. Аның белән аралашкан кешеләр барысы да аны коеп куйган артист иде, ди. Аның тавышы матур булган, икенчедән, бик хисле иде, диләр. Талант иясе. Образларны үтемле итеп күрсәтә алган. Һичшиксез, кыю кеше. Башкаларда да талант яшәгәндер, әмма беренчеләрдән булырга Сәхипҗамал батырчылык иткән.

Мәктәптә укыганда ул урыс театрына йөри, театр белән җенләнә. Татар театры туып кына килә, әмма анда ирләр генә уйный. Сәхипҗамал – Фатих Әмирхан белән күрше яшәгән кыз, ә ул – заманның иң прогрессив фикер ияләренең берсе. Габдулла Тукай, Хөсәен Ямашев белән дус. Шәһәр яшьләре бергә кайнашкан, милли үзаң ачылган вакыт, ник татарлар ябылып яши, ник татар шулкадәр консерватив дигән сораулар бимазалый. Шәригать кануннары көчле заман булса да, Сәхипҗамал театр идеясе белән янып, ярамый дигәнне атлап чыга; бәлки, башкалар да артымнан иярер дип уйлагандыр.

– Беренче татар актрисасы дигән данлы исем белән бергә аны тел белән мыскыллау белән чикләнмиләр, куып тотып кыйныйлар, буып үтерергә маташалар, Җаекта гастрольләргә барганда аңа хәтта пистолеттан аталар, чак кына исән кала... Бүгенге көн терминнары белән әйткәндә, буллинг корбанына әйләнә. Аны патриархаль җәмгыять кабул итми. Мондый хәлләр булуын белсә, чамаласа, бу адымга барыр идеме икән?

– Белгән, чамалаган булса да, ул кире борылмас иде. Сәхнә белән агуланган кеше үз хыялыннан баш тартмый. Табигатьләре шундый. Менә бүген артистларга карыйм, әлбәттә, XX гасыр башындагы шартлар белән чагыштырып булмый, әмма алар кечкенә хезмәт хакы алуга, тәүлек буена балаларын да онытып эшләргә туры килүгә, эт булып аруларына карамастан, сәхнәдән баш тарта алмыйлар. Сәхипҗамал да сәхнәдән ваз кичә алмаган. Әйе, аны җәберлиләр, ачлыкта, фәкыйрьлектә яшәгән чаклары күп була, аңа даими яныйлар, әмма ул татар театрын булдырам дигән идея белән яши.

– Сәхипҗамал Волжская – татарның иң кыю феминисты. Ул татар хатын-кызы да театрда эшләргә хаклы һәм гомумән хатын-кызлар ничек тели, шулай яшәргә хокуклы дип үз үрнәгендә күрсәтә. Патриархаль яшәешкә протест күрсәтү кебек яңгырый. Ул гомер буена мин булдырам, хатын-кызлар булдыра, татарлар менә шундый дип яшәгән дигән хис туа.

– Сәхипҗамал тормышын өйрәнү миндә күптөрле каршылыклы фикер тудырды. Аның шәригать кануннарын атлап чыгуы барыбер сораулар калдырды. Ул вакытта сәхнәгә аяк баскан хатын-кызлар әти-әни фатихасыннан баш тарткан. Хатын-кызмы, ир-атмы – бу гамәл бер кешене дә бәхетле итми. Сәхипҗамал – дини тәрбия алган кеше, ул чорда йөзен ачып, чәчен капламыйча кеше хозурына чыгу кая алып барганын, алда бәхет көтмәгәнен чамалагандыр. Бәлки, чамалап та бетермәгәндер. Кыз бала гына булган бит.

Ләкин шушы адымга бармаса, үзен корбан итмәсә, безнең бүген гөрләп торган театрларыбыз булыр идеме? Татар театры – безнең йөзек кашыбыз. Сәхипҗамалны хатын-кыз буларак кызганам. Кирәк булганмы бу корбан, юкмы дигән эчке бәрелеш бар. Өйдә тәти хатын булып яшәү дә, бәлки, аны бәхетле итәр иде, әмма милләт өчен бу югалту булыр иде. Үзен корбан итеп, сәнгатькә фидакяр хезмәт итүе өчен без аңа рәхмәтле булырга тиеш.

Ә патриархаль җәмгыятькә килгәндә, мин бүген хатын-кызлар үзенең асылын онытып бара дип, дилбегәне үзебезгә алуны артык дип саныйм. Акча да эшлибез, идарә дә итәбез, машина да йөртәбез, ирләр белән бергә рәттән чабабыз... Аллаһ Тәгалә юкка гына ирләр һәм хатыннар рәвешендә безне төрле итеп яратмаган, төрле сыйфатлар белән бизәмәгән, ул табигатьне бозарга кирәкми.

– Актрисаның мемуарында кызык бер тарих бар. Татар труппасы белән Семей шәһәренә бара һәм аларга анда спектакль куярга сәхнә бирмиләр. Башта татарның театры бармы дип мыскыл итәләр, аннары ничек инде татарча спектакль куясыз, бәлки, сез анда патшаны хурлыйсыздыр дип цензура кертәләр һәм тәүлек эчендә шәһәрдән китәргә кушалар. Актриса хурлана, әмма шәһәрдән китми, труппа ачлы-туклы яши, әмма сәхнә табып спектакль күрсәтә. Бу – патша заманы. Совет вакытында да, хәзер дә татарларга карата, татар телендәге проектларга карата «ә бәлки сез каршы эшлисездер» дигән сылтау белән эш ителә. Шул сылтау белән милли мәгариф тә тар-мар ителеп килә, театрлар да күзәтү астында.

– Сәхипҗамалны бик милли җанлы кеше дип күзаллыйм, ул чыннан да татарда ни өчен бусы юк, ни өчен без ябылып яшибез дип үҗәтләнеп эшли һәм яши.

● С.Гыйззәтуллина-Волжская җәмәгате Владимир Русинов белән. Ижау. 1924 еллар.

Ул булсын дип тырыша. Сез искә алган сюжет аның татар өчен янып-көеп яшәвенең бер кечкенә мисалы. Ул татар сәнгате урыслыкыннан ким булмаска тиеш дигән фикер белән яши һәм шул юнәлештә эшли.

Үзем театрларны Мәскәү сәясәте астында дип әйтә алмыйм. Татар театрлары күп очракта ирекле эш итә, үз фикерен җиткереп килә. Ниндидер коточкыч цензура астында эшлибез дип тә булмый (А.Әхмәтгалиева Чаллы драма театрында әдәби бүлекне җитәкли – ред.). Әмма мәктәпләрдәге татар теле белән булган вәзгыять – ул йөрәк авыртуы һәм бу чыннан да Россия сәясәте басымы белән эшләнде. Кызганычка, Татарстан берни эшли алмады, хәтта татар теле кирәкми диючеләрнең күп өлеше үзебезнең татар кешеләре булып чыкты. Бу – халык белән эшли белмәү нәтиҗәсеме, татар теленә карата мөнәсәбәт нәтиҗәсе булдымы – төпле анализ ясыйсы бар.

– Бер яктан актриса татарлар туган телендә сәхнәдә үз әсәрләрен куярга хаклы дип аяк терәп тарткалаша, икенче яктан урыс теле, мәдәниятенә мөкиббән киткән дигән хис кала. Фамилиясенә урысчалатып «Волжская» өлешен өсти, мемуарларында урыс режиссерлары, актерлары турында мөкиббән китеп яза, ул вакытта гадәттән тыш хәл булып саналса да, урыс кешесенә кияүгә чыга. Бу кимсенү комплексымы яки мода, мөгез чыгару булганмы?

– Әйе, ул вакытта катнаш никахлар сирәк күренеш булган, әмма ул мөгез чыгару яки шаккатыру өчен махсус урыс кешесе белән гаилә корыйм әле, димәгәндер. Актриса бик соң кияүгә чыга. 41 яшендә була ул, ә Владимир Русинов аңардан 9 яшькә кечерәк тә әле. Кечкенә деталь – никахларын теркәгәндә, Сәхипҗамалның яшен 21 яшь дип язалар. Хатамы, әллә махсус шулай язганнармы – белмим. Алар 1921 елның 8 гыйнварында язылышкан. Кияүгә чыгуы зур мәхәббәттән дә булмагандыр. Шулай да Сәхипҗамалны хәтерләүчеләр Русиновның аңа карата бик җылы карашта булганын, аның көен көйләп, һәрвакыт булышуын сөйлиләр.

Актриса – үзен беренче итеп күрергә күнеккән кеше, уйлаганын туры әйткән, капризлары да, мин-минлеге дә җитәрлек. Кияүгә чыкканда бер кочак чире була, әле үпкәсе, әле ашказаны авырта, болар хакында шул чордагы медицина белешмәләре сөйли. Ире аны бала кебек тәрбияләгән. Бәлки, Сәхипҗамал кияүгә чыгарга кирәк, тормышта таянырлык кеше булсын, дип никахлашкандыр. Аларның күршеләре Русиновны чуаш иде бугай, дип тә сөйли. Сүз уңаеннан, ул бай нәселдән, большевикларның сәясәтен кабул итә алмыйча аның әти-әнисе чит илгә китә, Владимир Николаевич исә шәһәрдә кала. Русинов ул вакытта Ижау шәһәренең башкарма комитет сәркатибе була. Ул Сәхипҗамал эшләгән рус театрына килеп йөргән, шунда танышып, аннан никахлашканнар.

Ә артистка үзе Казанга кайтырга тели, татар театрында уйнарга хыяллана. Кайта, әмма Казанда инде ул түгел, ә башкалар йолдыз. Афишада, матбугатта – Тинчурин белән Болгарская исемнәре. Аңа төп рольләрне бирмиләр. Актриса моңа гарьләнә, мин Казанга вак-төяк рольләр уйнарга кайтмадым дип үпкәләп, кире Ижауга китә. Ә анда – урыс театры. Ул шунда уйный, әмма бу аны канәгатьләндерми. Сәхипҗамал заводтагы эшче татар кызларегетләрен туплап, татарча театр түгәрәкләре оештыра. Мәрзия Миңлебаева аның театр түгәрәгенә йөреп данлыклы артисткага әверелә. Димәк, Волжская татарлыкка тартылу, сусау белән эшләгән.

– Актрисаның мемуарларын укыганда ул большевиклар фанаты булган дигән фикер туа. Кызылларны яклап язуы нәрсәне аңлата: Сәхипҗамал инкыйлабны куанып каршы алганмы, яки бу аның ниндидер бер хәйлә белән сакланырга тырышуымы? Кызыл террор вакытында татар зыялыларының байтагы, ялган донос нигезендә кулга алынып, төрмәгә утыртыла. Күпләрне атып үтергәннәр, кемдер сөргенгә җибәрелгән. Алар арасында татар драматурглары, артистлар, режиссерлар бар. Гаҗәп, Сәхипҗамал Сталин тегермәненә эләкми кала.

– Үзен ярлы гаиләдән дип ассызыклаганын әйттем, әмма бу алай түгел. Казанда үз йортлары белән яшәгән алар. Эзли торгач, Ижауда аның бертуган апасы яшәгәнен ачыкладык. Гражданнар сугышы башланганда алар бөтен хәзинәләрен алып Ижауга килеп төпләнгән. Азмы-күпме җитеш тормышта яшәгәннәр. Аннары, һәр кешегә үз тормышы кадерле. Сәхипҗамал гомерен саклап калу бәрабәренә яңа сәясәтне кабул итәргә мәҗбүр булган. Большевикларга каршы чыкканнарның язмышы ничек тәмамланганын үз күзләре белән күргән. Кемне атканнар, кемне ат койрыгына бәйләп өстерәп үтергәннәр, кемне асканнар. Дини тәрбия алган, күңелендә Аллаһка ышану булган актрисаның кеше рухына кизәнгән сәясәтне җаны белән кабул итүенә ышанып бетә алмыйм.

Кызыл террор елларында актриса ничек исән калган дигән сорауга җавап мондыйрак. Ул вакытта аның ире Русинов Ижауда НКВД системында эшли, ул озак еллар «особый сектор» бүлеген җитәкләгән. Авызны чамалап ачарга, карашларны яңа заман таләпләренә салып үзгәртергә туры килүен бәлки ул да аңлаткандыр...

– Кәрим Тинчурин, Габдулла Кариев, Мөхтәр Мутин һәм башкаларны хөкем иткәндә актрисаның роле нинди була? Ул аларның төрмәгә эләгүенә булышамы, әллә НКВД аны кулланганмы?

– Театр тарихын өйрәнгәндә КГБның кайбер архив документлары белән танышырга туры килде. Халык дошманнарын эзләү, ачыклау, шпионнарны фаш итү җыеннары – бу чорның куркыныч битләре. Театр утырышлары хәзерге К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры бинасында була. Ул вакытта Сәхипҗамал Ижауда яши, әмма бер җыелышка аны да чакыралар. Ире белән килүе билгеле. Аның ясаган чыгышлары сакланып калган. Җыелышны театрның парторгы Ишморатова алып бара. Сөйләшү беркетмәләренең күп өлеше «Туташ» романында бар. «Габдулла Кариев театрны таркаттымы?» – дип сорыйлар. Сәхипҗамал: «Кариевны гаепләү урынсыз, акчабыз да җитмәде, артистлар котыртуга бирелеп, үпкәләшләр аркасында таркалдык», – ди. Спектакльләрдән акча керми иде, Кариев безне ничек туйдыра алсын», – дип сөйли.

Тинчуриннар белән уртак фикергә килә алмыйча Ижауга чыгып китүенең сәбәпләрен сорыйлар. Актриса, туры сүзле булуым өчен мине яратмадылар, Казанга кайтсам да, миңа роль бирергә ашыкмадылар дип сөйләп, Тинчурин белән Болгарскаяга үпкәсен белдерә. Тинчурин һаман яшь егетләрне уйнап йөри дип тә чеметеп ала, әмма шул ук вакытта алардан халык дошманы да ясамый.

– Актрисаның соңгы еллары күп сораулар тудыра. Кайда үлә, ничек, кайчан җирләнә – гел буталчык мәгълүматлар. Аның җәсәден бер кабердән казып алып икенче кабер казу тарихында ачыклык бармы?

– Сәхипҗамал Казанга кайту хыялыннан баш тартмый, мин татар театрына кирәк, Казанымда үлеп, Тукай янында җирләнергә телим дип яши. Ул мондый эчтәлекле хатларны ТАССРның дәүләт оешмаларына юллый. Ире картайган көндә күченеп китүне өнәми, әмма Сәхипҗамал барыбер үзенекен итә. Кайталар, аларга Яңа бистәдә, Камил Якуб урамы, 2 нче йортта фатир бирәләр. Ире чирләп китә, психик авырулар диспансерына эләгә һәм шунда вафат була. Аннары актриса: «Мин бу фатирда тора алмыйм, иремнең өрәге яшәргә ирек бирми», – дип җәфалана һәм аңа фатирны Карл Маркс урамына алыштырырга ярдәм итәләр. Татар театрына якын гына. Волжская театрга гел йөрермен, дип хыяллана, мин театрга кирәк дип уйлый. Әмма ул теләгәнчә булмый, ара-тирә театр училищесына, премьераларга чакыралар, тик бу гына җитәрлекме... Үзенең кирәклеген тоеп, дәрәҗәсен белүләрен теләде дип сөйлиләр. Мондый мөнәсәбәт күрмәгәч, үзенә йомылган.

Берара театр мөдире Рәшидә Җиһаншина янына Волжскаяның күршеләре килеп, актриса урамдагы песиләрне җыя, алар белән сөйләшә, кайчак өен таба алмый, оныта, адаша, газны ачып калдырыр дип куркабыз, дип зарлана. Бу – шаһитларның хатирәләре. Сәхипҗамалның күршесендә яшәгән Равил Шәрәфи дә, аның, өен онытып, озатып куярга соравы турында хәтерли. «Хәле чыннан да начарайган, авыруы көчәйгән, туганнары булмагач, караулы, тук булыр» дип Дәрвишләр бистәсендәге картлар йортына урнаштыралар. Мин актрисаны кабул иткән, караган табибны эзләп таптым. Кәүсәрия апа исән-сау, ул аны яхшы хәтерли. Картлар йортында Сәхипҗамал апаның чире аза башлады, Волков урамындагы психодиспансер табибларына күрсәтергә алып бардык, дип сөйләде. Аңа деменция диагнозы куела һәм Чистай шәһәрендәге психоневрологик интернатка урнаштырырга дигән фикергә киләләр. Картлар йортыннан аны машинага утыртып, бер шәфкать туташы озата бара.

Чистайда Сәхипҗамал яткан вакытта эшләгән шәфкать туташын эзләп таптым. Ул аның ябык, хәлсез булуын, орден тагылган пәлтә кигән килеш алып килүләрен хәтерли. Үзе белән песи ияртеп килгән. Кашык тотып үзе ашый алмый, берсен дә танымый, сорауларга җавап бирми иде, дип сөйли ул ханым актриса турында. Озак яшәми анда Сәхипҗамал, шунда вафат була. Аны интернат янындагы зиратта башкалар кебек үк, исем-фамилиясез генә, номер белән генә җирлиләр. Хәнифә апа безгә зират булган урынны да күрсәтте. Берничә айдан соң Чистайга кинәт кенә Казаннан кешеләр килеп төшә. Алар Югары Совет президиумы рәисе Салих Батыев фәрманын – данлыклы татар артисткасының Тукай янында җирләнергә телим дигән васыятен үтәргә тиешбез дип аңлаталар. Ягъни аның җәсәде тиз арада Чистай зиратыннан Казандагы Татар зиратына күчерелергә тиеш. Төп бурыч СССРның халык артисты Фуат Халитовка йөкләнә. Төнлә кабер казыла, сөякләрне полиэтиленга төреп, шул ук төнне Казанга алып китәләр, Татар зиратында җирләү эшләре башкарыла. Тукай янында актрисаның кабер ташы куела. Алып киткән сөякләр чыннан да Волжскаяныкы һәм чыннан да Тукай янында ул җирләнгәндер дип уйлыйк. Алай түгел икән, гөнаһлыларны Аллаһ үзе кичерсен. Шушы җирләүдә катнашкан кешеләргә аерым бүләкләр дә бирелә, күрәсең, авызларын яптырыр өчендер...

Сәхипҗамал Волжская турында галим Җәүдәт Миңнуллин да җентекләп өйрәнгән. Ул да тарихи документлар юк дип сөйләде. Гәрчә актриса озын гомер кичерә, ул күп вакыйгаларга тере шаһит була. Ваемсызлыгыбыз, шәхесләр белән кызыксынмавыбыз, аларны барлый белмәвебез, зурламавыбыз аркасында, кызганыч, күпне югалтабыз.

Интернет челтәреннән алынды.

Рашат НИЗАМИ

Шахмат дәресләре



(Дәвамы. Башы 45 нче санда).

Менә бу сүзләрдән соң Шакирҗанның түземе шартлады! Шушы авылда туып-үскән, буын ныгыткан Шакирҗан үзен колхоз рәисе белән аяк терәп сөйләшерлек кешегә саный иде, шуңа да ул тел-фәлән яшереп тормыйча, күңелендәге уйларын ачыктан-ачык ярып салды:

– Оялмыйча колхозчылардан акча җыяр идеңме?.. Җитмәсә, пенсионер яшендәгеләрнең акчасы песи яларлык кына. Алга таба без менә шул хакта уйлашыйк әле...

Шакирҗан, әйтәсе килгән уйларына чумып, уң як терсәге белән өстәл өстенә таянды.

– Оптимизация дигән булып, авылның медпунктын яптылар. Аны, һичшиксез, яңадан аякка бастырырга кирәк. Анда телефон һәм су кертү күп хезмәт сорамас. Йә, кыскарту дигән булып, китапханәне дә яптылар, ди. Күз алдыңа китерәсеңме, авыл кешесенең кәефенә ник сугачак бит бу!.. Безнең авыл элек-электән укымышлы булган. Совет заманында ашык-пошык төзелгән фермаларның да рәте китте. Аларны ремонтлау кирәктер ләбаса...

– Син бу эшләрне миңа калдыр инде, – диде Хәснулла, серкәсе су күтәрмичәрәк.

Шакирҗан үзенең уй-фикерләренә, хыялларына баштанаяк баткан иде. Сүзен дәвам итте:

– Боларны бергәләп, килешеп эшләп карасак иде, дип әйтүем. Минем ниндидер орден яисә медальләргә омтылуым түгел бу, дөрес аңла. Намусым, вөҗданым кушканы өчен мин күп нәрсәләр эшләргә әзермен. Ата-бабамнар рухына, Ватан сугышында һәлак булган авылдашлар истәлегенә һәйкәл торгызсак та начар булмас иде, шулай бит?..

Бу сүзләр һәм тәкъдимнәрдән Хәснулла әллә ни егылып китмәде шикелле. Аның тирли төшкән маңгаена хәтта көлемсерәү төсмерләре җәелде:

– Боларның бөтенесе пафос кына! Бу хакта минем дә еш уйланганым бар. Әлеге син санап киткән эшләрне башкару өчен, беләсеңме, күпме акча кирәк булачак? Ә мине югарыдан көн аралаш сөт һәм ашлык планы белән интектерәләр, егетем...

– Ә менә мине берәү дә интектерми, үземә үзем хуҗа. Чамалыйсыңдыр.

Ул көнне ике арадагы кайнар бәхәс байтак дәвам итте әле. Бер караганда, икесе дә эчләрен бушаттылар, күңел түрендә оешып яткан әйтер сүзләрен ачыктан-ачык әйтеп салдылар.

Ахырдарак Шакирҗан бабасы Мөбарәкнең ачы язмышы турында, йөрәгенең иң яшерен түреннән сыгып чыгарган: «Колхоз безне зар елатты...» – дигән сүзләрен тәфтишләп-аңлатып сөйләмәкче иде, акылы җитеп, вакытында тыелып калды. Чөнки аның каршында колхоз тарихын, үткәннәрне, андагы фаҗигале язмышларны аңлардай, тәүбәгә килердәй кеше утырмаганы көн кебек ачык иде. «Авылда аягында көчкә басып торган колхозга җитәкче итеп мамыксыз, тамырсыз кешене җибәргәннәр», – дигәнрәк фикер калган иде аңарда.

* * *

Август уртасы. Җәйнең соңгы җилләре исә.

Әле кайчан гына яшькелт дулкындай тирбәлешеп утырган арыш һәм бодайлар тәмам тулышып, башакларын аска иделәр. Гүя, безне урып салыгыз, җилгәрегез, келәт-амбарларга урнаштырыгыз, диләр.

Шакирҗанның да арендага алган биләмәсендә бодайлар (берничә башакны уып карады!) шартларга җитеп энҗе бөртегедәй өлгерде, түземсезләнеп, урып-суктырганны көттеләр.

Беренче көн уңышын ук (аһ, андагы баш әйләнгеч көшел исләре!) үзе көйләгән җыйнак сараена урнаштырганнан соң, кичен соң гына кайтып, арып-талып, йокларга ятты.

Комбайнның, авыл урамын һәм күрше-тирәнең тынычлыгын алмыйм дип, авыл читендәге аулаграк бер почмакка урнаштырган иде. Иртән торып, ашап-эчеп алганнан соң ерак тыкрык почмагына килеп караса... ачу катыш имәнеп китте! Комбайнның салам төяү өчен тагылган әрҗәнең ике тәгәрмәче тиң шәлперәеп җиргә сеңгән... Якынрак килеп караса – кул пычкысы беләнме кисеп, гөнаһсыз тәгәрмәчләрнең икесен дә сафтан чыгарганнар.

Кем эше бу? Корткычлыкмы, әллә көнчелекме?.. Икесе дә булырга мөмкин. Ләкин бернинди эзләр-тамгалар, гаепләрдәй дәлилләр калдырмаган. Язмыш усал уеннарны уйнарга да күп сорап тормый икән, менәтерә.

Баш миенең кайсыдыр почмагында «Нишләргә?..» дигән сорау яшьнәп алды.

Каян сабырлыклар тапкандыр, хәлбуки, Шакирҗан уйлады-уйлады да милициягә бернинди хәбәр салмады. Шикләнүләр һәм мәшәкате муеннан булачак, дип гөманлады. Тәгәрмәчләрне көйләү-алыштыру байтак вакытны алды, уңышның вакытында җыелуына шактый зыян да килде ул чакта.

* * *

Сирәк кенә кайткаласам да, авылда без аның белән очрашмый калмыйбыз, әлбәттә. Икебез дә шахмат уенын яратканга күрә, җай табып, тотабыз да ярыш өстәле артына утырабыз. Сыйныфташым Шакирҗан үзгәрмәгән: күп сөйләшми, ләкин кызыклы яңа фикерләре белән мавыктыра, зиһенеңне төртеп уята, әллә нинди яңа идеяләр уйлап таба.

Шундый очрашуларның берсендә ул миңа болайрак сөйләп китте:

– Шахматта «ход конем» дигән нәрсә барын беләсең, ягъни ат йөреше. Чынлап та, гаҗәп нәрсә бит ул ат йөреше, шулай бит? Бер генә фигуралар да эшли алмаган «элмәкләр»не ясап кына тора ул, гайрәтен күрсәтә. Әле уңга, әле сулга, әле алга, әле артка сикерешләр ясый. Һәркайсы хикмәти адымнар! Көндәшеңне аудару, какшату һәм, ниһаять, җиңү өчен гаҗәеп мөмкинлекләр бар аңарда... Негр шахматчы, яһүд фермер булган дисәләр, ышанмыйм, ә безнең татар икесен дә булдыра!

Хыялланып китеп, хәтта ки ниндидер эчке бер хискә бирелеп, әлеге фәлсәфәсен тагын да үстереп, баетып җибәрде:

– Безнең бабайлар гомер буе диярлек ат өстендә яу чапкан. Шуның белән Европаны, аның байтак кыйтгаларын тезләндергән дә... Авылда атлар бетеп бара, туганкай. Менә нәрсә борчый мине. Атның күкрәге калкан кебек, яллары ялкын, бәкәл һәм тояклары яшен! Ә гәүдәсе... Монысын гади тел белән генә аңлата да алмыйм. Табигать безгә бүләк иткән менә шундый көчне, матурлыкны югалту зур хата булыр иде.

– Килешәм, – дидем, аны бүлдермәскә тырышып.

– Әйткәнемчә, атлар бит гомер буе татарның юлдашы, дусты, тугры хезмәтчесе булган. Тракторлар буразнага кергәч, атларның кирәге бетте диярлек, авылның бүгенге малайлары ат иярләү, ат атлану бәхетеннән мәхрүм ителде. Минем бабам Мөбарәк заманында өч баш ат тоткан... Менә шушы изге эшкә үз өлешемне кертәсем килә. Бабамның эшен, яшәү рәвешен дәвам итү – минем бурычым. Син мине аңлыйсыңмы?

– Аңлыйм, бик аңлыйм, – дидем, хуплавымны белдереп.

– Килешсәң, менә шул: мин якын киләчәктә нәселле атлар үстерәчәкмен! Дустым, син миңа догада, теләктә бул...

Безнең озын-озак сөйләшүләр ул көнне әнә шулайрак тәгәлләнде. Вакытлар узды, байтак сулар акты, фасыллар алмашынды. Аннары инде мин районда фермерлык мәйданына беренчеләрдән булып дәртләнеп вә ыргылып кергән Шакирҗан дустым Бикмөхәммәтов, аның уңышлары турындагы бик күп сәхифәләрне күреп тә, ишетеп тә, мәртәбәле газеталардан укып та, ихластан шатланып кабул итә идем.

* * *

Шунысын яхшы беләм: яңы эшкә, яңалыкка сусап торган бу азамат егеткә авыл җирендәге мәйдан гына тар иде. Күрәсең, шуңа да ул, район җитәкчелеге белән сөйләшеп, район үзәге читендәге шайтан таягы да үсмәгән, кысыр яткан буш-ташландык җирне арендага алды.

Ике ел дигәндә шул дүрт-биш гектар җирне аранлап һәм киртәләп, яшәр өчен шул биләмәнең алгы ягына ике катлы йорт-җир корырга да өлгерде. Себер һәм башка төбәкләрнең әллә кайсы нокталарына барып, гади атларны әйткән дә юк, гарәп чабышкыларына хәтле үзенең бер дигән сарайларына, утарына урнаштырды. Болын шикелләрәк бу утарда еш кына атлар кешни, яшел үлән уртлый, чабышып та алалар, алар янәшәсендә сөйкемле колыннар уйнаклый. Менә кайда ул табигатьнең идиллиясе! Хатыны Нәфисә хуҗалыкта исәп-хисап эшләрен башкарса, үсеп килүче сөлектәй ике уллары атлар һәм колыннар белән мәш килде, малкайларны тәрбияләү эшеннән дә читләшмәделәр. Аларның гаиләсе тулган ай шикелле түгәрәк һәм бөтен иде.

Әйе, уңышка бер селтәнүдә генә ирешү мөмкин түгел. Аңа сәгатьләп, көнләп, еллап ирешәсең. Ниһаять, алар тәрбияләп үстергән атларның район, тора-бара Казан һәм Россия күләмендәге бәйгеләрдә гел беренче урынны яулавын, чемпион булуларын сөйләп торуның хаҗәте бар микән? Боларны йөгертеп кенә узуның хикмәте шунда – безнең бит әле хикәятебезгә бәйле гыйбрәтле бер вакыйганы бәян итәсебез бар...

* * *

Көн арты көннәр уза тора.

Күпме генә мәшәкатьләр, хәл итәсе мәсьәләләр өелеп килсә дә, Аллаһ кушып, Шакирҗанның кылган эшләре, тормыш-яшәеше уңышлы гына бара. Язмыш аңа үз итеп елмайды дияргә генә кала. Көнозын кайнашуларны әйткән дә юк, ерак яки якындагы сәфәрләрдән соң арып-талып кайткач, гаилә җылысына сыенып, ашыйсы ризыгын ашый, эчәсе чәен эчә. Йокы туйдырып вакыт җиткәч, хәләл җефете җәйгән урын-җиргә, ак сырмалы юрган эченә чума. Күргән төшенә дә атлар керә аның.

Шулай берсендә, төш белән өн арасында саташып, кинәт уяна һәм гаҗәп... сүзсез эчке бер аваз аны каядыр чакыра. Бик сирәк тарта торган кеше булса да, сигарет пачкасына үрелә, ирексездән ишегалдына чыга.

(Дәвамы киләсе санда).

Җырчыны искә алдылар

Мәскәүнең Татар мәдәни үзәгендә күренекле татар җырчысы, композитор, быел май аенда бакыйлыкка күчкән, Ренат Ибраһимов истәлегенә багышланган кичә узды. Артист турында җылы истәлекләр белән уртаклашырга туганнары, дуслары, хезмәттәшләре җыелды.

Татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Фәрит Фәрисов сүзләренчә, чара баштан ук гаилә бәйрәме итеп уйланылган иде.

Мәскәүнең Милли сәясәт департаменты киңәшчесе Валерий Мищенко билгеләп үткәнчә, мәскәүлеләрнең төрле буыны Ренат Ибраһимовны һәм аның иҗатын хәтерли һәм ярата. Россия Мөфтиләр шурасы рәисенең беренче урынбасары, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Россия Мөфтиләр шурасы аппараты җитәкчесе Рушан Әббәсов сүзләренчә, Ибраһимов һәрвакыт Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсенең мәдәни тормышында актив катнашты, төрле чараларга йөрде, аларда чыгыш ясады.

«Мин – Ренат Ибраһимовның фанаты. Ул – тембр короле, андый тавышны беркайчан да ишеткәнем булмады. Бу безнең горурлыгыбыз, мирасыбыз», – дип билгеләп үтте җырчының якын дусты, Россиянең һәм Татарстанның атказанган артисты Владимир Кудашев. Ул үз вакытында җырчының визит карточкасына әверелгән «Наш город» җырын башкарды.

Сәхнәдә шулай ук композитор, музыкант Миләүшә Хәйруллина, опера җырчысы, Зур театр солисты Марат Гали, җырчы Мари Карне, Россиянең атказанган артистлары, Ибраһимовның дуслары Сергей һәм Николай Радченко, Татарстанның атказанган артисткасы Роза Хәбибуллина, композитор, пианист Семён Сон, Россиянең атказанган артисты Феликс Царикати, Россиянең халык артисты Владимир Девятов һәм башкалар чыгыш ясады. Александр Айвазов Ибраһимовның репертуарыннан «Любовь настала» җырын башкарды.

Мәрхүм артистның хатыны Светлана Ибраһимова оештыручыларга, ярдәм күрсәтүчеләргә рәхмәтләрен ирештерде.

Ф.Фәрисов мәрхүм артистның туганнарыннан Мәскәүнең Татар милли-мәдәни автономиясендә киләсе елны Ренат Ибраһимовка багышлау турындагы инициативаны хуплауларын сорады.

Мари Илендә очрашулар...

Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова Мари Иленең Бәрәңге районында булып кайтты. Моннан 90 ел элек татар районы буларак оешкан бу төбәктә 15 мең тирәсе кеше яши, шуның яртысыннан күбрәге – татарлар, Бәрәңгенең үзендә исә татарлар 80 процент. Галим Марсель Әхмәтҗанов язуынча, төрки-татарлар бу төбәктә болгар чорыннан ук яшәгән, ә Бәрәңгегә рәсми рәвештә нигез салыну вакыты дип 1552 ел күрсәтелгән. Бу нигезне дә Касыйм якларыннан килгән Чураш һәм Бураш исемле татарлар салган, дип язалар. Төбәк мари телендә Параньга дип атала һәм елга сүзен белдерә, ә борынгы фарсы телендә – изге җир дигәнне аңлата.

Ф.Бәйрәмова Бәрәңге бистәсенең Үзәк мәчете ифтарханә-мәдрәсәсендә дин сабагы алучы мөслимәләр, төбәк тарихчылары, милли активистлар белән очрашу уздырды. Аны мәчет имамы Рамил хәзрәт Зөлкарнәев башлап җибәрде. Язучы исә Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы турында җентекле чыгыш ясады.

Бәрәңге районында төбәк тарихы белән кызыксынучылар бар, бу хакта китаплар языла, авыллар тарихы турында Казанда да, Йошкар-Олада да телевизион тапшырулар эшләнә, фәнни җыеннар уздырыла. Биредә «Насретдинов укулары» дип аталган фәнни-мәгариф конференция узган, анда Казан, Мәскәү, Йошкар-Ола, Малмыж, Түбән Новгородтан һ.б. төбәкләрдән галимнәр, дин әһелләре, мәгърифәтчеләр катнашкан. 17 буын имам-мәгърифәтчеләрдән торган Насретдин мулла нәселен дәвам итүчеләр Бәрәңгедә бүген дә яши. Рәйхәнә Гаязова үзенең данлыклы нәселе турында ике томлык «Нәсел хатирәсе» дип аталган документаль китап язган, аны Йошкар-Ола шәһәрендә яшәүче милләттәшебез Фирзия Сабирҗанова ярдәмендә бастырып чыгарган. Дөрес, бу китап инде моннан ун ел элек Мари Иле башкаласында дөнья күргән, әмма ул бүген дә үзенең актуальлеген, мәгънәви мөһимлеген җуймаган. Биредә Бәрәңге төбәгенең борынгы һәм бүгенге тарихын да, милләткә хезмәт иткән дин әһелләренең бөек һәм фаҗигале язмышын да, Гаязетдин мулланың өч шагыйрь улы шигырьләрен дә, үткәннәрдән истәлекләр, тагы бик күп хәл-вакыйгалар турында укырга, тиңсез, сирәк тарихи фотоларны күрергә мөмкин. Рәйхәнә ханымның бабасы Гаязетдин хәзрәт Насретдиновны, «халык дошманы», дип, 1937 елны атып үтерәләр, ул чакта аңа инде 76 яшь була. Бу китап бер нәсел тарихы турында гына түгел, ул Бәрәңге төбәгенең энциклопедиясе, монда шәхесләр һәм милләт язмышы калку итеп бирелгән.

Ф.Сабирҗанова һәм Р.Гаязованың матбугачылык эше дәвам итә – 2017 елда алар «Чык тамчысы» дип аталган күләмле җыентык бастырып чыгара, анда Мари Илендә яшәүче татарларның үзләре язган шигырьләре һәм кыска хикәяләре тупланган. 2020 елда шушы ике фидакяр ханым җитәкчелегендә Йошкар-Олада «Самавия әби нәсыйхәте» дип аталган җыентык дөнья күрә, анда йөз яшькә җитеп килгән милләттәшебез Самавия апа Сафиуллинаның шигырьләре туплап бирелгән.

Ф.Бәйрәмова Бәрәңге районының Портянур һәм Мазарбашы авылларында да булды. Мазарбашы – бу төбәктә иң борынгы татар авылларының берсе, аның 1539 елда ук мәгълүм булуы архив документларында теркәлеп калган. Очрашуда катнашкан Наил Бариев үзенең туган авылы турында китап яза, ул Мәскәү, Казан, Киров, Йошкар-Ола архивларыннан күп тарихи документлар тапкан. Очрашу 1829 елда салынган тарихи мәчеттә булды, совет чорында аны колхоз идарәсе, китапханә итеп файдаланганнар. Элек Мазарбашында өч мәчет, данлыклы мәдрәсә булган, тирә-як татарлары төп дини белемне шунда алган. Мазарбашы шулай ук үзенең данлыклы ат базары, тукыма-комач, күн-тире фабрикалары белән дә билгеле. Авыл әүвәл Морзалар атамасын йөрткән, әмма тора-бара урыс документларында Алашайка, дип языла башлаган. Бу да тарихи бер ишарә... Авыл бүген дә ныклы тормыш белән яши, янәшәдәге Куян авылы белән икесенә бер урта мәктәп, анда татар теле дә укытыла, мәктәп Гайнан Кормаш исемен йөртә.

Язучы мари якларына сәфәрдән милләт хакында күп мәгълүмат туплап кайтты. «Бу төбәкнең тарихы бик борынгы, анда элек тә, хәзер дә иманлы, көчле рухлы татарлар яшәгән һәм яши, – ди ул. – Бәрәңгенең үзендә элек дүрт мәчет булган, хәзер ике мәчет эшләп килә, мәдрәсәдә балалар да, олылар да укый. Шушы мәдрәсәне үз акчасына салдырган һәм тоткан, хәләл ризык җитештерүче эшмәкәр Фәтбир әфәнде Хисмәтуллинга, анда халыкка дини белем бирүче җәмәгате Гөлүсәгә рәхмәт! Алар милләтне агарта. Әтисенең гомер буе җыйган нәсел архивын еллар буе өйрәнеп, компьютерда хәрефләп җыйган, үз акчасына китап итеп бастырып, милләткә тапшырган Рәйхәнә Гаязова сокландыра, югыйсә, ул һөнәре буенча геодезист-топограф бит! Ә нинди затлы китаплар нәшер иткән! Әле 2004 елда ук Мари Республикасындагы 106 авыл турында «Очерки истории сел и деревень Республики Мари-Эль» дип аталган китапның авторлар коллективы җитәкчесе булган, яшьлегендә – комсомолны, олыгайгач районның ветераннар советын җитәкләгән 80 яшьлек Фәүзия апа Мөхәммәтова-Чурашова бүген дә иң актив кешеләрнең берсе. Авариядән соң чирек гасыр буе кул-аяклары селкенмичә урын өстендә яткан, шул хәлдә дә Мисырга барып, дини гыйлем алган, намазын укыган, уразасын тоткан, «Сияние самоцветов» дип аталган интернет-кибет ачкан, аның аша асылташлар белән сәүдә иткән, компьютерлар төзәтеп, үз тормышын үзе алып барган Хәсән энекәшкә рәхмәт! Чирек гасыр буе баласын кашыктан ашаткан, бар эшләрендә аңа ярдәм иткән, янәшәсенә басып, намаз укыган, улының рәхмәт фәрештәсенә әйләнгән Рәйсә апа турында аерым китап язарлык! Портянур авылыннан чын мөселман әбисе Динә апа, аның иманлы гаиләсе, Мазарбашы авылыннан төбәк тарихчысы Наил Бариев, Фәйрүзә абыстай Вәгыйзова, моңлы итеп азан әйтү остасы Рафаиз Сафин, Бәрәңгедә очрашулар оештырган Әминә һәм Гөлфия сеңелләргә дә чиксез рәхмәтләрем!»

«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге.

Мәдәни җомга
25 ноябрь
№46, 2022

● Рәссам, шагыйрь Хәмит Латыйпов.

● «Чишмәгә бару».

Шигърияттә – рәссам, рәсемдә шагыйрь ул

Бериш иҗат ияләре олыгайган саен яшьлегендәге иҗат алымнарын кабатласа, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Х.Латыйповның иҗаты һаман яңара гына бара. Моңа кадәр Хәмит аганы агачны кисеп-уючы, балчыктан әвәләүче, фәлсәфи уй-фикерләрен кыска гына юллар белән әйтеп бирүче шагыйрь буларак белсәк, «Хәзинә» милли сәнгать галереясында рәсем сөючеләр аны яңа яктан ачты. Хәер, шул ук Латыйпов ул, күңеленнән ургыган милли хис тә, олы иҗатына карамыйча, үзен әллә кемгә куймыйча гади сөйләшүе дә, балаларча самимилеге дә шул ук. Бары хис-тойгылары агачта, балчык эшләнмәләрдә түгел, бütәнчә рәвеш алган.

Дөрес, Хәмит аганың төсле картиналарын элек тә күргән бар иде. Әмма шулкадәр зур күләмдә, барысын берьюлы тамаша кылгач, рәссамның иҗат куәсенә хәйран калырлык. Әле күп иҗат эшләре экспозициягә сыймый калган. Урын юктан да түгел. Х.Латыйповның һәр эше шулкадәр зур тәэсир көченә ия ки, аларны янәшә, бер-берсенә якын урнаштырып булмый. Юкса Л.Толстойның «Анна Каренина» һәм «Сугыш һәм солых»та күтәрелгән темаларны, геройларны бер романга берләштергән кебек күренеш килеп чыгар иде. Рәссамның бөтен картина, скульптураларын күрсәтәм дисәң, искиткеч зур мәйдан кирәк!

Бүген байтак рәссамнарның иҗатында пейзаж, натюрмортлар өстенлек алды, билгеле бер темага багышланган картиналар, бигрәк тә тарихи жанр, аеруча яшь рәссамнар иҗатында сирәк күренешкә әйләнде. Дөрес, яза белеп язсаң, алары да катлаулы. Әмма каен, миләш агачлары, алма-әфлисун сурәтләре белән милләтнең йөзен чагылдырып булса икән. Х.Латыйпов исә бернигә дә карамыйча, милли тормыш турында уй-фикерләре белән сәнгать чаралары ярдәмендә уртаклашуын дәвам итә. Хәмит аганы башка төрле итеп күзалдына китереп булмый.

Латыйпов тиз бирешеп, җиңелрәк жанрларга күчә торган түгел, күңеле нечкә булса да, тормышта ачыны-төчене күп татыган. Җиде айлык чагында әнисе җан биргәч, дүрт ел фашист лагерьларында интеккән үпкә чирле әтисе тәрбиясендә калу, алты яшендә әтисе белән бергә өй күтәрү, һәркайсы унышар сутый ике бакча карау аны физик һәм рухи яктан чыныктыра. Тугыз яшендә әтисе яңа хатын алып кайткач, баш бирмәс Хәмит өйдән кача. Әтисе вафатыннан соң унике яшендә бөтенләйгә – өйдән, унбиш яшендә авылдан чыгып китә. Шул гомердән бирле дөньяда берьялгызы яшәп, нык булырга да, эшкә дә өйрәнә. Халык бишегендә тирбәлеп үскән рәссамның иҗаты бүген шундый кимәлдә – чит бер планетада яшәүчеләрне татар милләте белән таныштыру кирәк булса, беренчеләрдән булып рәссам Хәмит Латыйповның картиналарын очырырлар иде.

Сурәттән-сурәткә яңа төсмер ала барган хатын-кыз, ана, туган җир, ата-ана йорты образлары рәссам Х.Латыйпов иҗатының милли асылын билгели. Балалар рәсемнәрен хәтерләтсә дә, картиналарны наив сәнгатькә карый дип әйтү дөрес булмас, чөнки һәркайсының анык идеясе, фикере, катгый төзелеше, композициясе бар. Бу хакта сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова белән фикер алышабыз. «Хәмит Латыйповның иҗаты – гаҗәеп күренеш. Картиналар милли эчтәлекле, ләкин самими сәнгатькә якын булса да, рус рәсем сәнгате гадәтләре буенча хәл кылынган. Туган йорт, ана, хатын-кыз образлары исә аны дөнья сәнгате югарылыгына күтәрә. Фигураларның яссы сурәтләнешендә кыпчак балбаллары белән охшашлык бар һәм сурәтләрдәге геометрик сызыклар, фигуралар рун язуын хәтерләтә. Хәмит аганың шигырь иҗат итүен белмәсәм дә, сызымнар, төс-төсмерләр, якты-караңгы, җылы-

● «Урып-җыю чоры».

● «Кошлар кебек».

● «Йөрәккә якын моң».

● «Җайдак җыры».

салкын буяулар каршылыгына корылган ритм аша аның шагыйрь икәнен барыбер чамалап булыр иде. Шигърияттә – рәссам, рәсем сәнгатендә шагыйрь ул. Аның керамикасы, агач эшләнмәләре, төсле картиналары бер-берсеннән аерылгысыз, бербөтен тәшкил итә. Бөтен эшләрендә гасырлардан килгән татар-мөселман мәдәнияте сәнгате традицияләре ярылып ята».

Х.Латыйповның 2003 елда Казанның «Матбугат йорты» нәшриятында үз рәсемнәре белән бизәлеп басылган «Күңелем сурәтләре» һәм 2006 елда Татарстан китап нәшриятында сынлы сәнгать әсәрләрен һәм шигырьләрен үз эченә алган «Галәми гамь – Вселенский лад» җыентыкларыннан тыш бер-ике данәдә үз акчасына китаплар чыгарганы билгеле. Шулай итеп, ул рәссам буларак кына түгел, педагог, остаз сыйфатында да тирән эз калдырды. Ул китапларның әлегә кадәр нәшриятләрдә күп тираж белән басылмавы күңелне әрнетә. Мәсәлән, агач ую сәнгатенә багышланган китабы – сәнгать мәктәпләре, училищеларда белем алучы яшьләргә әзер һәм бәһасез уку әсбабы. Х.Латыйпов картиналарының – шигърият, шигырьләрен исә рәсем сәнгате күзлегеннән карап өйрәнү дә кызыклы булыр иде.

Рәссам Х.Латыйповның сәнгать китапларын кулына алган кеше авторны бүген түгел, ерак үткәндә яшәгән һәм бакыйлыкка күчкән дип уйларга мөмкин. Шулкадәр талантлы агач уючыбыз, балчык әвәләүчебез була торып, аны сувенирлар ясауда файдаланмавыбызны тагын ничек аңлатырга?

● «Кич белән».

● «Кичке җыр».

● «Кунакка бару».

Хәмит ага осталыгын Мәскәү өлкәсенең «Богородская резьба» курсларында да, Туймазы шәһәренең фаянс-фарфор заводында да, Суфия Хәйбрахманның «Туран» фондында милли сувенирлар җитештерүче буларак та, сәнгать мәктәпләрендә белем биреп тә төрле өлкәләрдә сынаган. Әллә безнең агач кисеп-ую сәнгате бик алга киткәнме, яисә керамика, милли тәлинкәләр белән мактана алабызмы? Калфак-түбәтәйдән, каюлы күннән кала тагын нинди милли һөнәрләребез чәчәк ата? Х.Латыйповның исә кулыннан килмәгән эш юк. Иҗаты ургып чыга. Үзенә иркен остаханә биреп, яхшыдан-яхшы агач, балчык китереп торсаң, берүзе бөтен республиканы сувенирлар белән тәэмин итәрдәй эскизлар тудыра алыр иде! Янәшәсенә сәнгать белән җенләнгән унлап баланы китереп утырт. Тагын 40-50 елга агач, балчык сувенирлар өчен кайгырмасак та булыр иде. Ә безнең әлегәчә Хәмит агага Бакый Урманче премиясен дә биреп сөендергәнебез юк. Латыйповның уйга баткан карт скульптурасына карасаң, һичшиксез, Урманченың шул рухтагы мәшһүр агач скульптурасы белән уртаклык барлыгын сизәсең. Шул ук образлы фикерләү, импровизация, гомумиләштерү осталыгы. Хәмит агагага да булмагач, кем өчен генә соң Урманче премиясе?! Мәдәният министрлыгының бу премиясенә күптән лаек булып һәм дәүләт дәрәҗәсендәге югарырак бүләкләр алыр кимәлдә өлгереп җитсә дә, рәссамның кадерсез булып калуы үзәкне өзә...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

● «Декоратив чүлмәкләр».

● «Диңгез суүсемнәре».

● «Караңгыдан качу».

● «Уйга калган карт».

Мохтаҗларга ярдәм – хисапсыз савап

Авыр хәлгә тарыганнарга чын ярдәм күрсәтү, мохтаҗларга бушлай ризык тарату эшчәнлеген алып баручы «Приют человека» пунктларында теләгән һәркем җылы ризык ашап чыга ала. Бу мәрхәмәтлек белән бәйле социаль проектны башкалада оештырып җибәргән иманлы шәхесләрнең берсе – Казанның «Исламны кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Кабан арты мәчете имам-хатыйбы, Вахитов һәм Идел буе районнары мөхтәсибе Йосыф хәзрәт Дәүләтшин.

– Йосыф хәзрәт, бездә муллалар, хәзрәтләр бихисап булса да, төп вазыйфаларыннан тыш колачлы игелек эшчәнлеген дә тартып баручылар сирәк... Мөнә сез бу эшкә ничек алындыгыз?

– Бу эш кешелек тарихында үтә дә хәвефле ел булып истә калган 2020 елда башланды. Шул елның рамазан аенда, мәчетләр ябык булу сәбәпле, ифтар ашларын үткәрә алмадык. Шуңа күрә дә ризыкларны үтә мохтаҗларга ничек тә таратырга теләүчеләр табылды. «Приют человека» социаль реабилитация һәм адаптация үзәге генераль директоры, дустым Азат Гайнетдинов яныма килеп, игелекле ният белән булышырга тәкъдим итте.

Колхоз базары янындагы Б.Шаһиди урамында сукбайларны ашату өчен махсус вагон бар иде, ризыкны шунда таратырга булдык. Без рамазан ае буе аның беренче көннәрендә – 300 өлеш, аннары 700 өлеш ифтар ризыгын тараттык. Рамазан үтте, әмма әлеге башлангыч дәвам итте. Мохтаҗларны кайнар ризык белән тәэмин итүне туктатмадык. Шәһәр буйлап хәләл кафе хуҗаларына бардым, үзебезнең эш турында сөйләдем. Алар әкренләп бер көнне, ике көнне үз өсләренә ала башлады. Әүвәл, көненә 150 кеше ашатсак, аннары 350-400 кешене ашатуга күчтек. Татар күрми ышанмый, ди. Башта үзем өстәл артына утырып, ул мохтаҗлар белән таныша башладым. Баксаң, аларның 80%ы бик тә аз пенсия алучы әби-бабайлар, янгын чыгып кайгыга таручылар, аз керемлеләр, ялгыз калып өч-дүрт бала үстерүчеләр, гарип-горабалар... Аларның айлык түләүләрдән соң калган акчалары йә ашауга, йә кирәкле дарулар алуга гына җитә. Кайберләре: «Безнең ит алып пешерергә мөмкинлегебез юк. Ичмасам монда итле аш ашыйк, дип киләбез. Бер телем ипи белән аш, чәй – бик җитеп тора. Шулай тукланып көнебез үтеп китә! Акчабыз да янга кала, барыбер экономия бит бу...» – дип сөйлиләр.

Кызганыч, безнең халыкта балалардан да артык күп игелек өмет итеп булмый шул. Берәүнеке кредитын түли алмый, икенчесенеке өендә аракы эчеп, җан көеге булып ята... Шунысын да өстәп әйтәсем килә, мин үзем элек мондый урыннарда күбрәк беркайда да эшләмәүче, ялкау сәрхүшләрне генә ашатып яталар дип уйлый идем.

Сөйләшә-аралаша торгач, әби-бабайларның кайсы Мәскәү районының иң ахыргы йортларыннан, кайсы Азинодан ук килеп ашап китүләре хакында белдем. Бер тәлинкә шулпа ашау өчен килгән әбиләр трамвайга утырып, яңадан өйләренә кайтып җиткәнче әле күпме вакыт үтә бит... Шуннан оештыручылар Азат Гайнетдинов, Инсаф Вәлиев белән өчебез тагын киңәшләшеп алдык һәм «Приют человека» филиалларын, шушындый пунктларны Казанның башка районнарында да ачарга кирәк дигән нәтиҗәгә килдек.

– Бүген Казанда барлыгы алты пункт эшли. Аларны ачуда кыенлыклар тудымы?

– Әйе, аларның адресларын әйтеп үтим: Б.Шаһиди урамы, 26; Авангард урамы, 58; Ю.Фучик урамы, 52; Симонов урамы, 3; Гудованцев урамы, 6 һәм Липатов урамы, 6Б. Ризыкны якшәмбе көннән кала һәр көн 11.00-14.00 сәгатьләрдә таратабыз. Рәхим итегез!

Аларны ачу өчен, без шәһәрдә кибетләр, кафелар тотучы егетләргә чыктык. Чөнки алар мохтаҗларны яхшырак та беләләр. Кайда аз керемле пенсионерлар күп яши, кайда иске йортлар, олы яштәге халык кайда күбрәк булуын чамалыйлар. Әкренләп, 2021-2022 ел эчендә, шушы 6 ноктаны ачтык. Әлбәттә, андый чыгымлы эшләрне кафелардан ризык җыеп кына башкарып булмый. Күктән иңгән вакыт җитүе булгандыр, «Нәфис-косметикс» ширкәтенең вәкилләре әлеге эштә катнашырга теләвен җиткерде. РФнең Дәүләт Думасы депутаты Ирек Богуславский да электән үк шундый игелекле эшләр башкарган икән. Ул – безнең проект үсешенә зур өлеш керткән, мәрхәмәтлек проектыбызга бөтенләй башка тизлек биргән төп меценатларның берсе. Ил эшкуарлары өчен чын үрнәк. Алар белән берлектә без тиз арада павильоннар төзеп, аларны кирәкле җиһаз, корылмалар белән җайлап куйдык. Рәхмәт аусын, алар бу эшнең 70% ын күтәрде. Моннан кала һәр көн колхоз базары янындагы үзәк пунктка 400 порция ризык әзерләтү дә – алар өстендә.

– Калган пунктларыгыз кайсы мөселманнар булышлыгында?

– Үзәк ноктабыз «Нәфис»тә булса, Авангард урамындагы пунктны «Азу» һәм «Ханума» кафелары кайнар ризык белән тәэмин итә. Ю.Фучик урамындагы, «Хөзәйфә» мәчете янәшәсендәге пунктта да көненә 150 кеше туклана, бу мәрхәмәтлек эшен үз өстенә «Сөембикә» кафесы алды. Һәр пәнҗешәмбе анда «Әл-Бухари» кафесы әби-бабайларны тәмле пылау белән сыйлый, «Рәхмәтулла» мәчете (Симонов урамында) янәшәсендәге пунктка килүче мохтаҗларны «Ханский дом» төзелеш компаниясе ашата. Компания шушы мәчетне төзүдә дә генераль подрядчы һәм иганәче иде. Гудованцев урамындагы ноктабыз чыгымнарын хоккейчы Альберт Яруллин энесе Эмиль белән бергәләп каплый. Сөбханаллаһ, бер гаилә хисабына көн саен 130 лап кешене ашатабыз. Липатов урамындагы пунктны кайнар ризык белән тәэмин итүне исә «Medina Food» кафесы үз өстенә алды.

– Йосыф хәзрәт, мондый игелекле эшчәнлек шулай ук Татарстанның берничә районында да ике еллап дәвам итә бит...

– Әйе. Әле яңа гына Яшел Үзәндәге җәмигъ мәчете һәм колхоз базары янәшәсендәге Татарстан, 15а адресы буенча «Приют человека»ның яңа пунктын ачтык. Анда 150 ләп кеше ризыклана. Аның чыгымнарын Руслан Хәйретдинов җитәкчелегендәге «Итле Китчен» ризык пешереп тарату фабрикасы үз өстенә алды. Раббым эшләрендә бәрәкәт бирсен.

Башка пунктлардан: мондый нокта Бөгелмәдә ике ел буе тулы куәткә эшли, аның җитәкчесе – Рафаэль Яруллин; Норлаттагы пункт та шулай ук 2 ел тирәсе имам-мөхтәсиб Наил хәзрәт Әбелхановның тырышлыгы белән эшләп килә. Анда көненә 80 кеше туклана. Әгерҗедә мондый мәрхәмәтлек эшен мәшһүр фермер, иганәче булган Илшат Сәхиповның (урыны оҗмахта булсын!) уллары оештырып җибәрде. Алар 70 кешене ашата. Гадәттә, эш башлаганда: «Егетләр, без дә сезгә ярдәм итәчәкбез», – дип, башлыйбыз, ә бераз вакыт үтүгә, алар арбаны үзләре тарта башлый. Дусларыбыз Яр Чаллыда да, Түбән Камада да эшли. Алабуга каласында да һәр көнне 100 кешене ашаталар. Бүгенге көндә андагы егетләребез инде икенче ноктаны ачарга уйлый. Бу гамәлләрнең иң зур максаты – игелекле кешеләрне изге эштә берләштерү. Аллаһ Тәгалә: «Изгелек һәм тәкъвалыкта берләшегез, ярдәмләшегез», – дигән.

– Мондый хәйрия эше аена уртача нинди суммага чыга? Мохтаҗлар белән эшләү ничек оештырылган?

– Бер пункт эшчәнлеге кеше санына карап айга 180-270 мең сумга чыга. Мәсәлән, Казанда көн саен 1000 мохтаҗ кешене ашатсак, бу 80 мең сум тирәсенә төшә. Республика буйлап санасак, көненә 100 мең сум тирәсе буладыр. Әле ризыкланучылар саны кышын күбәя, билгеле, урамда йөрүчеләрнең тизрәк кайнар ризык ашыйсы килә. Салкында кайнар чәй күп китә.

– Ризыкланучылар арасында чын сукбайлар, сәрхүшләр дә байтактыр... Андыйларны социаль тормышка кайтару эше алып барыламы?

– Андыйларга Б.Шаһиди урамында төн кунсын өчен уннан артык җылы вагоннар хәстәрләдек. Базар җитәкчелеге дә ярдәм итә, анда сату-алу итүче халык та азык-төлек, төрле ризык, җылы киемнәр китерә. Әйе, халык арасыннан да ярма, үсемлек маен җәлләмәүчеләр, корбан итен китерүчеләр күп. Аларның һәммәсенә дә рәхмәт яусын!

Бар пунктларыбызда да видеокамералар эшли, тынычлык саклау буенча

Росгвардия белән килешүләр төзелгән. Ризыкланырга сәрхүшләр килә, билгеле. Тик безнең дә катгый таләп бар: аларны аек чакта гына ашатабыз. Аек булмасалар, алар тавыш күтәрә, бәхәсләшә, тарткалаша. Аңлату эшен алып барабыз. Кайберләрен әбиләребез әниләрчә сүгеп тә җибәрә. Тегеләре бераз оялып, китеп бара. Һәрхәлдә, социаль хезмәткәрләребез булган биналар хәвеф кнопкасы белән дә тәэмин ителгән. Шөкер, тәртип бозу очраклары сирәк. Ашыйсы килсә, эчүеннән дә тыелып тора беләләр.

Безнең эшчәнлек өчен бер иганәче «Ларгус» автомобилен бүләк итте. Хезмәткәрләребез көн саен шуңа утырып, башкала урамнарыннан сукбайларны җыярга чыгып китә. Аларны йә үзләре күреп ала, йә алар хакында безгә җирле халык үзе шалтыратып хәбәр итә. Казаннан һәм башкалага якын районнардан килгән хәбәрләрне телефон аша төнлә дә кабул итәбез. Бу нисбәттән тәүлек буенча эшли торган телефоныбыз: (843) 225-10-65.

Халык сукбайлардан чиркана да, курка да. Чөнки аларның кыяфәтләре дә куркыныч, йөзләре дә бик таушалган була. Сасы ис тә аңкып тора. Әмма алар бездән тагын да күбрәк шөлли кебек тоела. Чөнки кемдер аларга нидер ыргытып, кемдер тибеп, төкереп китә... Күбесенең рәсми документлары, медицина полислары юк, паспорт турында әйтеп тә тормыйм. Әмма мондый документ, рәсми кәгазьләрнең дә безгә кирәге юк. Бу мәрхәмәтлек эшен дәвам итүче хезмәткәрләребез арасында кайчандыр нәкъ шушындый хәлдә булганнар да бар. Сукбайларга – аерым караш, алар белән сөйләшү өчен шуларның берсен үзебез белән алып барабыз. Чөнки алар янына өстенә ап-ак күлмәк, аягына затлы аяк киеме кигән бәндә килеп сөйләшә башласа, алар аны җитди кабул итми. Алар андыйларның сүзләренә ышанмый да... Үзләренә булышлыкка каршы килмәүчеләрне: «Әйдә, безгә кил. Туйганчы ашарсың, мунчада юынып чыгасың. Чип-чиста киемнәр бирербез, чәчләреңне кыскартырбыз. Ә аннары, калырга теләмәсәң, кире урамга кайтып китәрсең», – дип юмалыйбыз. Безгә иярганнәр чиста киемнәрне сөенеп кия. Форсаттан файдаланып, шул хакта да әйтим, әгәр дә кемнәрнеңдер үзләренә кирәкмәгән кием-салымнары бар икән, рәхим итеп, аларны Б.Шаһиди, 26 адресына китерә ала. Әмма, зинһар өчен, киемнәрне башка пунктларыбызга китермәгез. Анда ул киемнәрне кабул итәргә шартлар юк.

Сукбайлардан соңрак кына: «Рәсми документларың, туганнарың бармы?» – дип сорыйбыз. Әкренләп паспортларын торгызабыз. Юристларыбыз бар. Күбесен дәүләт карамагындагы картлар йортларына илтәбез. Ә чирләре көчәйгәннәрен хастаханәләргә салабыз, чиста киемле сукбайларны табиблар да җирәнмичә карый, булыша. Берничә хастаханәнең баш табиблары белән дуслыгыбыз, хезмәттәшлегебез бар. Урамда яшәп, таш өстендә йоклап, вакытында ашамаганнарның иммунитетлары бик тә зәгыйфь, кайсысының инде гангрена башланып, кулы чери башлаган була, кайберсе бүсер чыгудан берничә ел буе газап чигә... Мәрхәмәтлек кылырга теләүче табиблар белән аңлашып эшлибез, алар операцияләр дә ясыйлар. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы, Ашыгыч ярдәм күрсәтү хезмәте белән дә килешүләребез бар. Һәммәсенә Аллаһ Тәгаләнең рәхмәте яусын!

Вакытлыча яшәү урынында бүгенге көндә утыздан артык кеше яши, шуларның, әйтик, алтысы – хатын-кыз, унысы – чын сукбай... Кышын анда иллеләп кеше кабул итәбез.

– Алар арасында эшлисе килүчеләр бармы соң?

– Дөресен әйткәндә, күп еллар буе урамнарда сукбай булып йөрүчеләр – алар хәлсез кешеләр. Аларның иртәдән кичкә кадәр эшләргә хәлләре юк, организмнары нык таушалган, сәламәтлекләре беткән.

Вакытлыча яшәү урынында хәле калмаган сукбайларның кайберсе аңына килгәнче карантин бүлмәсендә атна буе диярлек йокларга да мөмкин. Әмма без аларны эш белән тәэмин итәбез. Кулларына көрәк бирәбез, кышын тирә-юньне үзләре кардан көри, кайсылары шундагы махсус мунчаны яга, андыйларга әле бераз сәдакасын да бирәбез. Күңелләре була. Моннан кала, әле «Трудяги.рф» дигән оешмабыз бар. Диспетчерларыбыз эш бирүче оешмаларга шалтыратып, аларга эшчеләр тәкъдим итә, оешмалар белән килешүләр төзибез, без – шушы сукбайлар хезмәте өчен бер гарант, оешма хезмәт хакын безгә күчергәч, эшчеләребезнең кулларына таратып чыгабыз. Башкача мөмкин түгел, чөнки андый халыкны эшләтеп, бик күпләр хезмәт хакы түләми. Әкренләп аякка баскач, бераз акча күрә башлагач, кем – үз гаиләсен, кем үз туганнарын барлый башлый... Бездә чакта алар коммуна булып яши, аларны эчертмибез, исерткеч эчемлекләрдән тыябыз. Әйтергә кирәк, «Трудяги.рф» сайты аша һәркөн уртача 300-400 кешегә эш бирәбез. Чөнки безнең шефлык астында әле Казанның «1 нче төзәтү үзәге»ндә утыручы кешеләр дә бар.

– «Чишмә» проектыгыз белән дә таныштырып үтегез әле...

– «Приют человека» – ул бит дәүләт оешмасы түгел. Шуңа күрә без бергәләп утырып киңәшләшәбез дә, тагын савaплы эшләргә алынабыз. Менә «Чишмә» проектыбыз да шундыйлардан. Суның күләме яки сыйфаты белән авырлыклар булган урыннарда артезиан коеларын казый башладык. Бүгенге көндә 6-7 коены сафка бастырдык инде. Моның өчен белгечләр су булган урынны билгели, җир бораулана, фильтр системасы көйләнә, кирпечтән чишмә корылмасы төзелә. Бер чишмәне хәстәрләп ачу 1,5-2 млн сумга төшә. Сәдака бирүчегә бар хисап-отчетларыбызны күрсәтәбез, кем безгә ышана, кем мондый савaплы гамәлләр кылуга битараф түгел, сәдакасын бирә. Үрнәк итеп күрсәтердәй һәм халыкта иң популяр булган коебыз Усад мәчете ишегалдында урнашкан. Анда һәрчак чират тезелгән.

– Йосыф хәзрәт, мохтаҗларны кайнар ризык белән сыйлауга әйләнеп кайтсак, сез бу нисбәттән яңа хәбәр дә яздырыгыз бит әле. Шул хакта да берничә сүз әйтеп, бу әңгәмәбезне тәмам кылыйк!

– Әйе, шушы арада Ирек Богуславскийның әнкәсе Гайфулла кызы Зәйнәб әбиебез ахирәткә күчте һәм аның рухыннан дип, Татарстандагы бар пунктларга килүче мохтаҗларны ашаттык. Әлхәмдүлиллаһ, ике атна буе 10 пункт аша 16 610 порция кайнар ризык өләшенде. Күпме халык, татары да урысы да аның рухына дога кылды. Бу – бик изге эш һәм яхшы ният. Чөнки, безнең халыкта вафат булган әти-әниләр рухына багышлап изге эшләр кылу аз әле. Бу хакта видеоязма эшләгәч, тагын ике-өч гаилә безнең белән элемтәгә чыкты. Алар да мәрхүм әти-әниләре рухларына савап булып барсын дип, мохтаҗларны ризыкландырырга булды. Әйткәнебезчә, Казанда 1000 кешене бер көн тукландыру да уртача 70-80 мең сумга төшә.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ЯЛГАНГА ТӨРЕЛГӘН ФАҖИГА

Гааганың округ суды (Нидерланд) 2014 елның 17 июлендә Украина күгендә МН-17 рейслы Boeing777 очкычын һәлакәткә китергән сәбәпләрне атаган һәм аларны кылуда гаепле дип табылган затларны (россиялеләр И.Гиркин белән С.Дубинский һәм украин Л.Харченко), читтән торып, гомерлеккә ирекләреннән мәхрүм иткән. Искә төшереп үтик, Амстердамнан (Нидерланд) Куала-Лумпурга (Малайзия) юнәлгән очкычта ул чакта 298 кеше һәлак булды. Аның «Бук» ЗРК ракетасы белән бәреп төшерелүе дә ачыкланды. Җентекле тикшерүләрдән соң, суд ракетаның үзатамалы ДНР контролендә булган Первомайск ягыннан җибәрелүен ачыклаган. Суд шулай ук очкыч җимерелгән мизгелдә ДНР саклану министры И.Гиркин (Стрелков) Россия президентының ул чактагы ярдәмчесе белән элемтәдә булуын да ачыклаган, шуңа аларны, әлеге очкычны бәреп төшереп, оешкан төркем составында эш итүдә гаепләгән. Гаага суды 2014 елның маеннан Россиянең ДНР хәрбиләрен әзерләвен, аларны сугыш кораллары һәм азык-төлек белән тәэмин итүен, хәрби акцияләрне координацияләп, сугыш хәрәкәтләрендә дә катнашуын ачыклаган. Мәскәү исә гаепләүләрне кире кага, судны сәяси карар чыгаруда гаепли. Сугыш хәрәкәтләре барган зонада һава киңлекләрен ябмауда ул Киевне дә гаепли.

НАТОның Парламент ассамблеясы альянсның Мадридта үткән саммитында Россияне «террорчыл дәүләт» дип тану турында бертавыштан резолюция кабул иткән. Анда оешма әгъзаларына Россияне, бүгенге режим сакланганда, «террорчыл дәүләт» дип танырга катгый төстә тәкъдим ителә. НАТО һәм Россия арасында моңа кадәр төзелгән килешүләр, шул исәптән НАТОны киңәйтмәү турындагы килешү дә, гамәлдән чыгарыла. Документта альянс әгъзалары «агрессия» фактын һәм «террорчыл эшчәнлеген» тикшерү һәм җавапка да тарту ниятендә Халыкара трибунал булдырачагы турында да әйтелә. Моңа кадәр охшаш документларны Латвия, Литва, Эстония, Польша, Чехия һәм ПАСЕ да кабул иткән иде, ә бу көннәрдә андый резолюция инде Европа Парламентында да каралачак.

Башка вакыйгалардан игътибарны: Ак йортның Украинага ярдәм итүгә Конгресстан тагын 37,7 миллиард доллар күләмендә акча соравы; Польша хөкүмәтенең Россия тышкы эшләр министры С.Лавровка ОБСЕның 1-2 декабрьдә Лодзь каласында узачак Министрлар советы утырышында катнашуга виза бирмәве; Кремльнең матбугат хезмәте башлыгы Д.Песковның, Украинадагы махсус хәрби операция анда хакимиятне алыштыруны максат итми, дип белдерүе; климат буенча Шарм-әл-Шәехта үткән очрашуда (СОР27) катнашучыларның йомгаклау декларациясе текстыннан канәгать булмыйча таралуы һ.б. җәлеп итә.

Фоат УРАЗАЙ.

Бер җыр мең

Татарстанның атказанган артисты, Казан шәһәре филармониясе солисты Гөлшат Имамиева белән Урал якларында йөреп кайтырга туры килде. Мәктәпләрдә, мәдәният йортларында эшлекле очрашулардан соң, җырчы башкаруындагы «Ашкыну», «Назлы җыр», «Рәхмәтлемен Ходайга», «Сагыну», «Кичер, әнкәй» кебек җырлар меңнәрчә күңелләрне кузгатты, аны алкышлар белән кабат-кабат сәхнәгә чакырдылар.

● Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Данис Шакиров белән еш аралашырга туры килә.

● РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Альберт Әсәдуллин да Гөлшат Имамиеваның җырлавын ярата.

● Татарстанның атказанган артисты Газинур Фарухшин белән.

● Режиссер, РСФСРның атказанган артисты Наталья Бондарчук, кинорежиссер, Россиянең халык артисты Алла Сурикова белән Ригада очрашкан мәл.

Гөлшатның балачагын да бергәләп күз алдыннан үткәрдек. Ул җырлы-моңлы гаиләдә үсә. Әнисе Талиянең бишек җырларына халкыбыз моңнары кушыла. Ә инде әнисенең Савиново бистәсендәге өйләреннән ерак түгел генә яши торган апалары килсә, өй концерт залына әйләнә дә куя. Фәрзәнә апасы баянда уйный, әнисе икенче апасы белән җырлый. Гөлшат та кечкенәдән үк моңлы көйләр суза башлый. Балалар бакчасында да, Казанның үзе укыган 49 нчы рус мәктәбендә (анда класстагы 40 баланың бишесе генә рус милләтеннән була) дә җырлый ул, яңа көйләр дә өйрәнә. Укытучысы Роза Мифтахова, гадәттә, мандолинада уйный, кыз җыр суза. Белем учагында Тукай музее оештырылып, аны ачу тантанасына кунак булып килгән Туфан Миңнуллин, Сибгат Хәким, Роберт Миңнуллин, Фәнзаман Баттал алдында да чыгыш ясый кыз. Шунда Сибгат ага: «Бу кызыгыз мәктәбегезнең сандугачы!» – дип, тәгаенләп әйтә. Фәнзаман ага исә фикер-тәэсирләр дәфтәренә, «Гөлшат Минһаҗева (кыз фамилиясе) «Кыр казы», «Әллүки», «Тәфтиләү» кебек халык җырларын тулы аһәңе белән башкара! Туган телен белмәсә, шушы моң, шушы сәләт күмелеп каласы булган лабаса! Мин ышанам: бу тавышны әле халкыбыз радиодан, сәхнәдән дә ишетеп куаначак», – дип язып калдыра.

Укытучылар кызчыкны музыка мәктәбенә бирергә киңәш итә. Әмма берсе заводта, икенчесе кибеттә эшләүче әти-әнисенең минингит белән авырганнан соң бик үк сау булмаган олы балалары – улларын да махсус мәктәпкә йөртәсе бар, тормыш-көнкүрештә дә төрле мәшәкатьләр чыгып тора. Ул арада Гөлшат та музыка мәктәбенә укырга керү яшен уза. Кызчык чын сәхнәгә беренче тапкыр әнисенә ияреп чыга. Талия апа эшләгән кибет тимер юл оешмасына карый, аларның офислары, концерт залы да бар. Барлык тантаналар, бәйрәмнәр шунда үтә. Әлбәттә, концертлар да куела. Оешманың сандугачы Талия апа бу концертларга, берике җыр өйрәтеп кызы Гөлшатны да үзе белән алып бара башлый. Булачак артист шунда беренче җырларын башкара. Аңа бүләк бирәләр. Ә андый яулык, йомшак уенчыклар кибетләрдә дә юк заман...

Кызның җәйге каникуллары әнисенең туган ягы Кама Тамагы районы Каратал авылында дәү әни, дәү әти янында уза. Гөлшатны авылга, әнисенең олы апасының кызы белән бергә кайтаралар. Казан кунакларын анда, марҗалар, дип йөртсәләр дә, кызлар үпкәләми. Авыл кызлары белән бер басуны да калдырмый, бергәләп чабулыйлар. Күрше Кыртапа авылына кадәр барып чикләвек җыю, борчак басуында яшел кузаклар белән сыйлану, күмәк хуҗалык рәисе килә дип, кереп качулар, яңгыр теләп ботка пешерү, узып баручыларны су коендырулар – барысының да ләззәтен татый кызый. Аннары бензовоз, сөт, икмәк төягән машиналарга утырып, 40 чакрым ераклыктагы Тенькигә барулар... «Барыбер тыныч, рәхәт иде» – дип искә ала җырчы бу вакытларны.

Инде яшьлекнең мәктәп этабы да тәмамланып килә, һөнәр сайлар вакыт җитә. Кыз документларын Казан педагогика институтындагы филология факультетының рус теле һәм әдәбияты бүлегенә тапшыра. Әмма музыкаль белем дә булмагач, нота да белмәгәч алмаслар инде, дигән уйны җиңеп, әнисе белән үтеп барышлый музыка училищесына кереп чыгасы итәләр. Ә анда килгән яшьләрне җырлатып карау бара. Җырлый Гөлшат. «Тагын да югарырак алып җырлый аласыңмы?» – диләр. Әлбәттә! Вокал буенча конкурстан узып, тавышы педагогларның күңелләренә хуш килгәч, артыгын сораштырып тормыйлар, кызны кабул итәләр. Бәхет китерә торган уку йорты була ул. Биредә кыз язмышын, гомер юлдашын очрата. Булачак ире Дамир белән бергә укырга керәләр. Ноталарны өйрәнү генә түгел, фортепианода уйный белү дә сорала. Әти-әнисе дә кызның музыка училищесына керү шатлыгыннан өйләренә фортепиано алып куя. Яшьләрнең бәхетенә сольфеджио укытучысы бик сабыр була. Кыз фломастер, карандашлар белән язып ноталарны да өйрәнә. Елап беткән чаклары да булгалый. Әмма тырышлык үзенекен итә, бар авырлыклар да артта кала.

Училищедан соң консерваториягә юл ачыла. Ул әүвәл профессор Владимир Вороновта белем ала. Соңгы курста үскәндә үк, үзенә кумир итеп күргән, опера җырчысы буларак та, үзенең тавыш культурасы һәм моңы белән хәйран иткән Зилә Сөнгатуллинада укыйсын белгәч, Гөлшат беркадәр каушап та кала. Куркып кына килеп кергән яшьләрне Зилә Даян кызы үзенең ачыклыгы, мәрхәмәтлелеге, тирән белеме белән үзенә карата.

Консерваториядә укыганда ук Гөлшат Имамиева Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә эшкә урнаша. Консерваториядә распевка ясагач, хорга килә торган була. Ире белән бергәләп сәнгатькә хезмәт итү башлана. Бер ай эчендә программа әзерлиләр. Гөлшатка ике бүлектә дә катнашырга кирәк. Яңа гына эшкә урнашкан кыз калфак та кия белми. Сәхнә артында ярдәм итәм, дип торучы да юк. Шунда баш хормейстер Венера Гәрәева, «Әйдә балам, менә болай иттереп кенә куйыйк», – дип булыша. Булдыра дип, ялгыз җырлый торган партияләрне дә бирәләр. Венера Гәрәева «Бөдрә тал» ны өйрәтә, яшь ханымга «Сара», «Рамазан» кебек җырларны да ялгыз башкаруны ышанып тапшыра, Гөлшат ире Дамир белән «Булат белән Мәйсәрә»не дә җырлый. «Мин Венера Гәрәевага бүгенгегә кадәр рәхмәтле», – ди ул. Аннары җырчы Нәфисә Васыйлова, Ания Туишева, Шамил Әхмәтҗанов, Әмир Хәйдәров, Габдулла Рәхимкулов кебек элгәрләребез белән бер сәхнәдә чыгыш ясарга туры килүен дә олы бәхет дип исәпли.

Сопрано тавышлы җырчы Г.Имамиеваны Казан шәһәре филармониясенә дәшеп алалар. Тагын олуг артистлар белән бер сәхнәдә эшләү. Чит илләрдән кунаклар килгәч, иң әүвәл халкыңның милли мәдәниятен күрсәтү мәслихәт. Шуңа да филармония артистларына еш кына хөкүмәт оештырган чараларда җырларга туры килә, дәрәҗәле кунаклар каршында чыгышлар ясыйлар. Башка халыкларга ихтирам йөзеннән японча, вьетнамча махсус җырлар өйрәнәләр. Ә мәрхүм Шамил Зиннур улы Закиров исә, Гөлшат Имамиеваның җырлаганын тыңлаганнан соң, Камал театрында аңа аерым гына концертын куярга тәкъдим итә. Бу җырчы өчен зур затлы тамаша залында беренче соло концерты була.

Шундый хәл дә була. Гөлшат Имамиеваны Камал театрында концертта җырларга чакыралар. Рус җырын башкарырга

йөрәкне кузгата

● Тормыш иптәше Дамир Имамиев белән һәрчак иңгә-иң.

кирәк. Сәхнәгә чыгар минутлар җитә, никтер бер кеше дә микрофонны бирми. Җырчы, сәхнәдә микрофон бардыр, дип чыгып китә. Музыка башлана, җырларга кирәк. Трибунада беренче Президентыбыз М.Шәймиев сөйләгән микрофон тора. Гөлшат трибуна янына баса да тулы тавышка җырлый. Икенче куплетны башлар алдыннан, микрофон алып чыгып бирәләр. Минтимер аганың «О-о-о нинди җырчы, нинди тавыш!» дип әйткәнен соңыннан килеп сөйлиләр.

Филармониянең икенче зур эше – татар сәнгатен дөньякүләм дәрәҗәдә таныту. Г.Имамиева өчен Россия төбәкләренә, чит илләргә, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләгәндә үк башланган, гастроль сәфәрләре дәвам итә. Җырчы аяк басмаган ил дә юктыр, дисәк, Гөлшатка Кытай белән Австралиягә юл сабарга туры килмәгән әле. Гыйрак башкаласы Багдадта ансамбль белән барып җырлап кайтса, 1999 елда «Казан нуры» оркестры белән Германиягә юл тоткан. Алар, Казанга килгәч, филармония артистларының җырлаганын бик ошата, үзләренә дә чакырып китә. Зал тамашачы белән тулы, төрле шәһәрләрдә яшәүче татарлар җыелган. Концерт барганда сәхнәгә кем чыгасын немец телендә игълан итәләр, шуңа нәрсә әйткәннәрен аңлап та булмый. Гөлшат, оркестрга кушылып, алар сораган «Ашкыну»ны җырлый. Алар исә акапелла җырлый дип игълан иткән икән. Алдан рухи әзерләнмәгән булса да җырлый Гөлшат. Немецлар исә җыр сәнгатен бик ярата, күтәреп алалар. Италиядә, Испаниядә дә шулай. «Казан» бию ансамбле, фестивальләргә чыкканда, Г.Имамиеваны үзләре белән алып барырга тырыша. Чөнки ул теләсә кайсы мәйданчыкта үзенең сопрано тавышы белән микрофонсыз акапелла җырлый ала торган солист. Бер елны ул «Казан» бию ансамбле белән Франциянең Сан-Жирон, Сан-Годас шәһәрләренә дөнья халыклары фольклоры фестивалендә чыгыш ясый. Шунда французлар җырчының сопрано тавышын «могҗизаи тавыш» дип атый. Гөлшат Туниста татар халык җырын башкара. Күрәсең көйгә хисләнеп, биеп тә алгандыр. Берзаман залда – аншлаг. Кул чабалар. Мөселман иле булса да, алар татар халкының җырлы биюен яратып кабул итә. Гөлшат башкаруындагы җырлар Нью-Йорк, Сан-Францискода да яңгырый. Җырчы Латвияне аеруча ярата. Финляндиядә дә милләттәшләребез залны тутырып килә. Кая барсалар да, концертның үз тамашачылары табыла. Татар милләте моңлы җырлары, дәртле биюләре белән аерылып тора, концертлар да югары дәрәҗәдә уза, чит илләрдәге фестивальләрдә дә татар җырларын күтәреп алалар.

Г.Имамиевага Мәскәү, Уфа, Сергач якларына да күп йөрергә туры килә. Бервакыт ул Мирсәет Сөнгатуллин белән бергә Курган өлкәседәге бер авылга бара. Концерт башлана, залда барысы да елый, баксаң, 25 ел буена татар артистларын тыңлаганнары булмаган икән.

Соңгы елларда җырчының яңа сәләте дә ачылып киткән, филармония җырчылары да хәзер киң профильле артистларга әверелгән. Г.Имамиева җырлы тамашалар өчен сценарийлар яза, спектакльләр куя, үзләре уйный, җырлый. Әйтик, Гөлшат иҗат иткән «Австралиягә Сабантуйга» дип исемләнгән музыкаль-театраль тамаша аеруча уңышлы чыккан. Анда һәр персонаж автор тарафыннан уйлап табылган, тормышта килеп чыккан көлкеле вакыйгалар да күп кертелгән. «Әпипә» музыкаль киносына да төшкәннәр. «Көтегез, без киләбез!» дип исемләнгән музыкаль комедия дә тиздән зәңгәр экраннарга чыгачак. Аның сценарием Ләйсән Мәхмүтова, Гөлшат Имамиева, Алсу Сөнгатуллина, артистларның гастроль тормышына кагылышлы хәлләргә нигезләп язган. Әлбәттә, бу җырчы артистларның тормышын җанландырып та җибәрә. Алар үзләрен бөтенләй икенче ракурста ача. Тормышта килеп чыккан мәзәкләр дә кулланыш таба.

Әмма Гөлшат иҗат кешесе булса да, аның өчен гаилә беренче урында кала. Гөлшат гастрольләргә әзерләнә башласа, суыткыч ризык белән тула. Ире Дамир белән чиратлап гастрольләргә йөриләр, ә кайвакыт балаларын туганнарына калдырып та, ул белән кыз үстерәләр. Консерваториядә укыганда ук, II-III курс имтиханнарын тапшыра-тапшыра алып кайткан улы Әмир инде югары уку йортын тәмамлаган, үз эшен тапкан белгеч. Әминә исә мәктәп бусагасын атлап чыгарга әзерләнә. Ә инде әниләренең өйдә булуы барысына да бәйрәм. Аш-суга оста әниләре аларны ит бәлеше, өчпочмак, пәрәмәч һәм башка камыр ризыклары белән сыйлап кына тора.

Гомер уза, Гөлшат Имамиеваның татар сәнгатенә хезмәт итә башлавына да өч дистә ел узып киткән. Гастрольләр, алкышлар, рәхмәтләр белән бизәлгән бәрәкәтле еллар булган ул!

Сөембикә КАШАПОВА.

● Александр Градский белән очрашу истәлеге.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

26 ноябрь (шимбә). ***Җомадел әүвәл аеның 2 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 11.42 сәгатьтә калка, 16.46 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.42 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмләрәк һәм күбрәк ашау тәлгә зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Глицеринлы лимон

1 лимонны сүрән утта 10 минут пешерәләр, согын стаканга сыгалар. Шуңа 2 аш кашыгы глицерин һәм стакан тулганчы бал кушалар. Сирәк кенә ютәлләгәндә, көненә берничә тапкыр 1әр чәй кашыгы кабалар. Каты ютәлләгәндә, көненә 6 тапкыр 1 әр чәй кашыгы эчәләр. Башка дарулар булышмаганда да, мондый лимонлы ширбәт ютәлне яхшы баса. Лимонны алма серкәсе белән дә алыштырырга ярый.

27 ноябрь (якшәмбе). ***Җомадел әүвәл аеның 3 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 12.07 сәгатьтә калка, 18.08 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.39 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп тупланудан күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Кытай кагыйдәләре

Борынгы кытай табибләре һәрвакыт сәламәт, озак вакыт яшь һәм чибәр булуның алтын кагыйдәләрен язып калдырган. Менә алар: биткә ешрак массаж ясарга кирәк; чәчне ешрак тарау зарур; аскы һәм өске тешләр һәрвакыт бер-берсенә тиеп торсын; авыз гел ябык булсын; авызда һәрвакыт төкерек булсын; сулышның җиңел булуы шарт; йөрәк тыныч тибәргә тиеш; акыл һәм хәтер уяу булсын; арканы төз, туры йөртергә кирәк; эчне сыйпаштыргалап алу файдалы; күп сүз – юк сүз, аз сөйләргә өйрәнү мөһим; тән тиресе дымлы, майлы булсын; ешрак киерелү файдалы – сеңерләр гел тартылып-сузылып торсын, чөнки алар аша яшәү энергиясе ага.

28 ноябрь (дүшәмбе). ***Җомадел әүвәл аеның 4 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,12.38 сәгатьтә калка, 19.43 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.35 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Сихәтле суган

Сугандагы С витамины организмның саклагыч көчләрен активлаштыра, аңардагы үсемлек антибиотиклары – фитонцидлар авыру китереп чыгаручы бактерияләрне

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

үтерә, ә магний иммун системаны ныгыта, стресска бирешмәүчәнлекне көчәйтә. 4-5 кыяк суган һәм 1 бәйләм петрушканы вак кына турап, тоз сибәләр, 10 минуттан соң шуның өстенә кабыгы әрчелгән 1 лимонны ваклап турыйлар, үсемлек мае сибәләр дә, итле ризыклар белән ашыйлар. Яки 1 бәйләм яшел суганны турап, бераз эремчек яки вак угычта уылган сыр кушалар, тоз сибеп, каймак яки йогурт салып болгаталар.

29 ноябрь (сишәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 5 нче көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 12.57 сәгатьтә калка, 21.20 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.32 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

30 ноябрь (чәршәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 6 нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 13.10 сәгатьтә калка, 22.52 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.30 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

1 декабрь (пәнҗешәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 7 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 13.19 сәгатьтә калка, 0.20 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.28 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

Гаймориттан – дәфнә мае

30 г вакланган дәфнә яфрагын 1стакан үсемлек маенда җылы урында 5 тәүлек төнәтәләр. Марля аша сөзгәч, көнгә 3 тапкыр һәр борын тишегенә 1әр тамчы тамызалар. 2-3 көннән томау бетә, борын “йомшара”, эрен агып чыга һәм баш җиңеләеп кала.

2 декабрь (җомга). ***Җөмәдел әүвәл аеның 8 нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,13.27 сәгатьтә калка, 1.44 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.25 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Себер бавырсагы

Ярты литр сөт, 100 г эретелгән атланмай, 5 йомырка, 1 аш кашыгы шикәр, тоз кирәк, бераз коры чүпрә кушарга да була. Камыр басып, иллеләп кисәккә бүләләр, алардан түгәрәкләр әвәләп, тастымал астында 20 минут кабарталар. Аннары һәр түгәрәкне якынча 5 мм калынлыктагы кабартма итеп җәяләр дә, кул белән әкрен генә тартып, тагын юкарталар. Тирән казанда яки табада кайнар майда йөздереп кыздыралар, өстеннән дә шул кызган майны гел салып торалар. Бавырсак кабара башлый һәм алтынсу төскә керә. Кәгазь тастымалга алып, артык маен сеңдерәләр дә, шикәр оны сибәләр.

Юмор остасы

(Рәшит Кәрип улы Зәкиевкә 85 яшь)

Республикабызда укучыларга юмор остасы буларак яхшы таныш ул. Рәшит Кәрип улы Зәкиев 35 ел Татарстанның төп сатира-юмор журналы – «Чаян»ны җитәкли, аның баш мөхәррире булып эшли. Юмор жанрына бик җитди карарга кирәк дип саный Рәшит. Бу мәсьәләдә философларча фикер йөртә ул: юмор күп кенә кыенлыкларны җиңәргә, гаиләдә килеп чыккан низагларны көйләргә булыша, дипломатик проблемаларны җайга сала. Юморда озак яшәү серләре яшерелгән дип исәпли Рәшит.

Аның белән Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында татар теле һәм әдәбияты бүлегенең бер группасында укыдык. Рәшит факультетның татар телендә чыга торган «Әдәби сүз» газетасын чыгаруда актив катнашты. Бу газета коридорның бер башыннан икенче башына кадәр сузылган басма иде. Газетаны даими яңартып тордылар. Анда студентларның тормыш-көнкүреше белән бергә алар иҗат иткән әдәби әсәрләр дә басылды. Шунлыктан Р.Зәкиев редакторлык хезмәтенә студент еллардан ук өйрәнде дияргә була.

Укыган чорда без тулай торакта ике ел бер бүлмәдә яшәдек. Рәшитнең чисталык, пөхтәлек яратуы хәтердә калган. Ул чорда тулай торакның иң чиста бүлмәсенә конкурс игълан ителә иде. Иң чиста дип табылган бүлмәләргә телевизорлар, радиоалгычлар бирелде. Безнең бүлмә еш кына җиңүче булды.

Без туган көннәрне дә гадәттә Рәшит белән бергә үткәрә идек. Яшь аермабыз бары бер көн, мин аннан бер көнгә өлкәнрәк.

Рәшит Азнакай районының Тымытык авылында туып-үскән. Бу авыл бераз район үзәге дә булып торды әле. Безнең чорда югары уку йортларында укучы егетләр хәрби хезмәтне дә шунда үттеләр. Диплом белән бергә аларга кече лейтенант дәрәҗәсе дә бирелде. Алар дүртенче курстан соң хәрби лагерьда ике, соңгы курстан соң бер ай осталыкларын чарлады. Аннан соң хәрби дәрәҗә алу өчен дәүләт имтиханы тапшырылды. Ә Рәшит Зәкиев сәламәтлеге буенча хәрби хезмәттән азат ителгән иде. Шуңа күрә ул безгә караганда университетны бераз иртәрәк тәмамлады һәм эшкә җибәрелде: Дөбъяз районының «Колхозчы» газетасында хезмәт куйды. Хәтерлим әле, эшли башлагач ул миңа хат та язып җибәргән иде. «Егетләр, монда мин түгел, сезнең берәрегез эшләргә тиеш. Дөбъяз Арчага терәлеп кенә тора», – диелгән иде хатында.

●«Чаян» журналы редакциясе коллективы шимбә өмәсендә.

Рәшит Дөбъязда 1960-1962 елларда эшләде, аннары район бетерелде. Р.Зәкиев Октябрь (бүген Норлат) районында оешкан зона газетасына күчте. Ул анда 1962-1967 елларда хезмәт куйды. Редакторлары да республиканың иң талантлы журналистларыннан берсе Мәрди Рафиков иде.

Аннары Рәшит республика газетасы «Социалистик Татарстан»ның үз хәбәрчесе булды, төрле районнарга йөрде, республика тормышын өйрәнде. Ленинград югары партия мәктәбендә укып кайткач, Р. Зәкиев инде шактый көч туплап килгән Кама автомобиль заводы эшчәнлеген республика матбугатында яктыртты. Тормыш тәҗрибәсе туплап өлгергән Р.Зәкиевне 1972 елда партия эшенә күчерделәр – Татарстан өлкә комитеты инструкторы итеп билгеләнде. 1975 елдан Рәшит кабат матбугатта, бу юлы инде ул – «Чаян» журналының баш мөхәррире.

– 1923 елда ук, журнал чыга башлаганда эшкә керешкән хезмәткәрләребез дә юморның мәгънәсен яхшы аңлаган. «Чаян»ның беренче баш мөхәррире Фәтхи Бурнаш була. Данлы традицияне Әхмәт Исхак, Мирсәй Әмир дәвам итә. 1956 елда алар инде журналны рус һәм татар телләрендә чыгаруга керешәләр, – дип искә ала Рәшит. – Журналның тиражы 870 мең данәгә кадәр җитә. Бу чыннан да журналыбызның чәчәк ату чоры була. Хәтерлим әле, шулай бервакыт, Мәскәүгә командировкага баргач, «Союзпечать» киоскына зур чират күрдем. Мин дә Революция мәйданындагы шушы киоскка тыгылдым. Минем чиратсыз керүгә кешеләр ризасызлык белдерде, мине сүгәргә тотындылар. Нинди кыйммәтле товар сатулары белән кызыксындым. «Чаян»ның яңа саны килгән икән. Мин шатлыгымнан рәхәтләнеп көлдем. Чиратта торучылар мине бик үк акыллы түгел дип уйлаганнардыр, мөгаен.

Юморның мөһимлеген аңлатып, әңгәмәдәшебез аның дәүләтнең чикләрен киңәйтүе турында да әйткән иде. Журналны Израильдә һәм Болгариядә дә беләләр икән. Бу илләрдә «Чаян»ны алдырып укучылар була. «Чаян» журналын хәтта Болгария Президенты Желю Желев укыган. Ул рәхмәт йөзеннән Рәшит Зәкиевкә автограф белән үзенең китабын да җибәргән.

«Чаян» журналын яздырып алып укып баручылар арасында Свердловск өлкә губернаторы Эдуард Россель, шулай ук Герман Греф, хәтта Анатолий Чубайс та була. Ул бервакыт Казанда булганда, «Чаян»ны бик яратып укуы турында әйтә.

Р.Зәкиев карашынча, Советлар Союзының таркалуы юморның да зәгыйфьләнә төшүенә китерә, «Чаян»ның стратегиясен үзгәртергә туры килә. Шулай да коллектив журналның рухын саклап калырга тырыша.

Рәшит хатыны – табибә Салия белән ике кыз үстерәләр. Миләүшә тарих фәнен сайлый, Карлыгач исә юристлыкка өстенлек бирә.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Тормыш савыты

Өлкән сыйныф шәкертләре мәдрәсәдә дәрес башланганны, хәзрәтнең кергәнен көтеп утыра.

Ниһаять, кыңгырау тавышы ишетелә, мөгаллим сыйныф бүлмәсенә өч литрлы буш банка тотып керә. Исәнләшкәннән соң, шәкертләр урыннарына утыра.

– Бүген сезнең белән тормыш турында сөйләшербез. Кулыма тоткан банка турында нәрсә әйтә аласыз? – дигән сорау бирә мөгаллим.

– Ул буш, – ди шәкертләр.

– Дөрес әйттегез, – ди мөгаллим һәм өстәл янындагы кечерәк капчыктан буш банкага ташлар тутыра.

– Банка тулдымы? – дип сорый.

– Тулды, – диләр барысы да.

Мөгаллим өстәл янындагы икенче капчыктан шул ук банкага борчак тутыра. Борчак таш арасына кереп тула.

– Банка тулдымы? – дип сорый.

– Тулды, – диделәр һәммәсе.

Мөгаллим өстәл янындагы өченче капчыктан шул ук банкага ком тутыра башлый. Ком таш һәм борчак арасына кереп тула.

– Банка тулдымы? – дип сорый мөгаллим.

– Тулды, – ди шәкертләр.

Мөгаллим шәкертләргә аңлатып бирә:

– Банка – безнең тормышыбыз, ә ташлар – тормышыбыздагы мөһим нәрсәләр, бу – гаилә, балаларыбыз, безнең өчен бик мөһим булган нәрсәләр. Борчак – артык мөһим булмаган нәрсәләр. Мәсәлән, яңа костюм яки машина һ.б. Ком – бик мөһим булмаган, әмма тормышта кирәк булган ваграк нәрсәләр. Әгәр сез тормышыгызны ком тутырудан башласагыз, таш һәм борчакка (бик мөһим нәрсәләргә) урын калмаячак.

Төпле җавап

Акыл иясеннән сораганнар:

– Сезне кешеләрдәге нәрсә гаҗәпләндерә?

Акыл иясе аларга:

– Кешеләр балачактан туя һәм өлкән кеше булырга ашыга, аннан соң үскәч, яңадан бала чагына кайтырга омтыла. Кешеләр байлык артыннан куып, сәламәтлекләрен югалта, аннары байлыкларын үзләренең сәламәтлекләрен кире кайтару өчен тота. Киләчәк өчен борчылып уйлап, бүгенгесен онычалар. Бүген дә, киләчәктә дә рәтләп яши алмыйлар. Беркайчан да үлмәячәк булып яши, беркайчан да рәтләп яшәмәгән кебек үләләр, – дигән.

Игелек кылу

Элегрәк бер шәһәрнең өч бай кешесе яшәүчеләргә игелек кылырга уйлаган. Һәркайсы игелек өчен берәр тонна алтын әзерләгән.

Беренче бай үзенең бөртекле алтынын очкычка (самолетка) төяп, шәһәр өстенә сипкән. Бу хәлдән соң яшәүчеләргә артык файда килмәгән, тормышлары яхшырмаган. Алар шәһәр буйлап бик вак бөртекләрне эзләп, җыеп гаҗизләнгән.

Икенче бай үзенең алтын ком өемен эретеп, алардан алтын акча тәңкәләре суктырган һәм шәһәрдә яшәүчеләрнең барысына да берәр тәңкә өләшеп чыккан. Кешеләргә ул акча күпкә җитмәгән... Бу хәл турында шәһәрдә яшәүчеләрдә татлы хатирәләр генә калган.

Өченче бай алтын ком тавын сатып җибәргән, ә аның акчасына ярлыларга йортлар төзеткән, аларны эш урыннары белән тәэмин иткән, аларның балаларына, оныкларына балалар бакчалары, мәктәпләр салдырган. Чыгымнарын үзе түләп барган.

Һәр бай үзеннән бер тонна алтынын шәһәрдә яшәүчеләргә игелекле эшләр өчен сарыф иткән. Бу эшләрнең нәтиҗәләре төрле булган.

Еллар узган, баштагы ике байның игелеге турында шәһәр архивындагы язмалар аша гына белеп була. Өченче бай турында аның салдырган бакчаларында, мәктәпләрендә укучылар фәлән бай төзеткән бинада укыдык, дип горурланып сөйлиләр. Дин тотучылар аның рухына дога кыла. Ул байның юмартлыгы, шәфкатьлеге, зирәклеге турында хәбәрләр шәһәрдә яшәүчеләр авызыннан төшми...

Ярдәмне дөрес сорау

Урамда бер сукыр кеше утыра. Янында буш эшләпә һәм ярдәм сораган язу: «Мин сукыр кеше, зинһар, ярдәм итегезче».

Берәү аның яныннан узып барганда туктады һәм язуга карап торды. Инвалид алдындагы эшләпәдә биш-алты бакыр акча ята иде. Ул кеше эшләпәгә берничә бакыр акча ташлады һәм ярдәм сораган язуны алып, анда нииндидер сүзләр сызгалап, яңадан урынына куйды. Аннан соң үз юлы белән китеп барды.

Кичкә таба бу кеше сукыр кеше утырган урын яныннан яңадан узды. Эшләпә тулы акча иде. Ул гарип янына килеп исәнләште, аның хәлләрен сорашты. Сукыр бу кешене тавышыннан таныды. Инвалид бәндә булышлык күрсәткән өчен, аңа зур рәхмәт әйтте һәм үзен кызыксындырган сорауны бирми булдыра алмады:

– Әфәндем, сез ярдәм сораган кәгазьгә нәрсә яздыгыз? – диде.

– Мин бернинди усал, ямьсез җөмлә язмадым. Андагы сүзләрне башкачарак итеп үзгәрттем, – диде дә китеп барды.

Яңа язуда болай язылган иде: «Хәзер матур яз ае дип әйтәләр, кызганыч, мин аның матурлыгын күрә алмыйм шул».

Нияз БИШБАЛТА туплады.

МК тамаша залларына чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

25 ноябрь – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
26 ноябрь – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
27 ноябрь – 12.00 – «Бию пәрие» (И.Зәйниев). 18.00 – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
29 ноябрь – зур залда – «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев). Кече залда – «Көл» (К.Митани).
30 ноябрь – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).
1 декабрь – «Дон Жуан» (Ж.Б.Мольер).
2 декабрь – «Сәфәр» (А.Шакиров).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

25 ноябрь – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).
26 ноябрь – «Мәдинә» (И.Зәйниев).
27 ноябрь – «Беренче театр» (Г.Камал).
29 ноябрь – «Полиционер» (И.Зәйниев).
30 ноябрь – «Төш» (Т.Миннуллин).
1 декабрь – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).
2 декабрь – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

25 ноябрь – 18.30 – Театр буенча сәяхәт. 19.00 – «Әлфия» (И.Зәйниев).
26 ноябрь – зур залда – «Царевна-лягушка» (Н.Гернет). Кече залда – «Бүре җиләге» (Р.Зәйдулла).
27 ноябрь – фойеда – «Тыпырдык» (И.Зәйниев). Зур залда – «Щелкунчик» (Э.Т.А.Гофман).
2 декабрь – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

27 ноябрь – 13.00 – «Жизель» балеты (А.Адан). 18.00 – «Щелкунчик» балеты (П.Чайковский).
1 декабрь – «Щелкунчик» балеты (П.Чайковский).

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

25 ноябрь – Чаллыдан Игорь Лерман җитәкчелегендәге камера оркестры концерты. Катнашалар: Татарстанның атказанган артисты Д.Саттаров (скрипка), халыкара конкурслар лауреатлары П.Савочкин, Н.Горшкова (скрипка), Э.Әхмәтова (фортепиано). Программада Ф.Мендельсон, П.Чайковский, И.Брамс, И.Альбенис музыкалары.

26 ноябрь – С.Гобәйдуллина исемендәге «Concordia» XII халыкара заманча музыка фестивале кысаларында «Советлары союзы кинофильмнарыннан музыкаль әсәрләр» дип исемләнгән концерт. Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестры башкара. Дирижер – Сергей Скрипка.
27 ноябрь – Балалар өчен «Lego music» дип исемләнгән интерактив уен.
28 ноябрь – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты җырчы Альбина Шаһиморатова концерты. Концертмейстер – Елизавета Дмитриева. Программада М.Глинка, А.Римский-Корсаков, С.Рахманинов, Ф.Лист романслары.
29 ноябрь – Халыкара конкурслар лауреаты Зөлфәт Фәхразиевнең фортепиано концерты. Программада композиторлар И.С.Бах, Л.Бетховен, Ф.Шуберт, И.Рахманинов музыкасы.
30 ноябрь – С.Гобәйдуллина исемендәге «Concordia» XII халыкара заманча музыка фестивале кысаларында концерт. Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестры уйный. Дирижер – Валерий Полянский. Солист – Татьяна Полянская (фортепиано). М.Таминдарова җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы дәүләт камера хоры катнаша.
2 декабрь – М.Тәминдарова җитәкчелегендәге дәүләт камера хорының 15 еллык юбилеена багышланган концерт. Кичәдә С.Гобәйдуллина исемендәге заманча музыка үзгәненең дирижеры Анна Гөлишамбарова җитәкчелегендәге оркестры катнаша.

Көтеп көткән бәхет

Татарстанда 54 яшьлек хатын-кыз быел июль аенда беренче тапкыр әни булган. Эльвира белән Рамил сабыйлары тууны 30 ел көткән, биш тапкыр ЭКО ясаткан. Бу хакта Республика клиник хастаханәсе сайтында хәбәр ителә. Йөклелегенең 9 атнасына якынлашканда, хатын-кызны саклануга яткыралар. 14 атналык срокта аналык муентыгына җөй салырга туры килә. Ике атнадан өенә кайтаралар, әмма бер айдан Чаллыдагы Ашыгыч ярдәм хастаханәсенең гинекология бүлегенә кертәләр. Баланың вакытыннан алда туу куркынычы зур булганга, бер атнадан булачак әнине Республика клиник хастаханәсенең Перинаталь үзәгендәге патология бүлегенә китерәләр, ул дарулар эчәргә һәм ятып кына торырга тиеш була. Йөклелекнең сигезенче аенда кесарев кисеме ясап баланы дөньяга тудыралар. Яңа туган бәбиләр реанимациясе бүлегендә җитлегеп беткәч, кыз баланы 30 ел көткән әнисе янына кучерәләр.«Барысы да әйбәт булачагын белдем. Ышандым! Яхшы табиб кулына эләгү дә бик мөһим. Минем белән шушы юлны узган һәр табиб алдында баш иям», – ди Эльвира.

(“АиФ-Казань”).

Кем гаепле?

Уильям Джеймс Сайдис XX гасыр башындагы иң атаклы вундеркинд була. 11 яшендә Гарвардка кабул ителә, 6 яшендә сигез тел белә, аның IQ күрсәткече 250-300 баллга җитә. Әтисе – Украинадан Америкага күчеп урнашкан яһүд Борис Сайдис – Гарвард университетын тәмамлый һәм анда психология укыта. 1898 елда туган улы әтисе экспериментлары объектына әйләнә, ул яшь ярымлык чагында The New York Times газетасын укырга, ике яшь ярымлык чагында машинкада инглизчә һәм французча басарга өйрәнә. Биш яшендә малай иң катлаулы тимер юл расписаниесен яттан белә, тугыз яшендә уникеле логарифмнар системасын эшли. Әтисе Уильямның казанышлары турында фәнни журналларга мәкаләләр яза, 1911 елда Америка мәгариф системасын тәнкыйтьләп китап бастыра, анда үз укыту системасын мактый. Алты яшендә Бруклиндагы дәүләт мәктәбенә укырга кергән Уильям ярты ел эчендә җиде еллык программаны үзләштерә. Шул вакыттан бирле аның бөтен гомере репортерлар тыкшынуы астында үтә. Газета-журналларда басылган йөзләрчә мәкаләдә малайның нинди ачышлар ясаячагы фаразлана, аның сәләтенең тумыштан булуымы, әллә инде әтисенең инновацион тәрбия ысуллары нәтиҗәсеме икәне турында бәхәсләр кыза. Шулкадәр күп игътибардан малайның нервлары какшый, аны 1910 елда шифаханәгә ялга җибәрәләр. Ул күп халык каршында лекцияләр укый алмый башлый. 1914 елда сәнгать бакалавры дипломы ала. 1915 елдан Хьюстон университетында математика укыта, докторлык диссертациясе яза. Аның һәр гамәле матбугат чараларында яктыртылып бара, журналистлар аны эзәрлекли. Сайдис Гарвард университетына кире кайтып, юридик факультетка укырга керә, тик аны өч елдан соң ташлый. Репортерлардан качып, һаман бер шәһәрдән икенчесенә күчә, гади клерк булып эшли. Үн ел тыныч яши, романнар яза, тик 1937 елда журналистлар аны эзләп таба һәм мәсхәрәле мәкалә чыгара. Тагын эзәрлекләү башлана. 1944 елда, 47 нче яшендә ул, тарихка керерлек бернинди ачыш ясамыйча, Бостондагы тулай торак бүлмәсендә инсульттан җан тәслим кыла.

(“The Wall Street Journal”).

Фән аңлатырмы?

Урта диңгездәге Сардиния утравында йөзьяшәрләр саны арта бара. Галимнәр исә һаман моның сәбәбен ачыклый алмый. Британиядәге биотехнология компанияләреннән берсе утрауның көнчыгышындагы Ольястрада яшәүче 12,6 мең кешедән 230 меңләп биологик проба алган. Әлеге биологик материалларны өйрәнеп, британиялеләр озак яшәү серенә төшенмәкче була. Эш шунда: Ольястрада һәр 2 мең кешегә бер йөзьяшәр туры килә, бу АКШ һәм Бөекбритания кебек алга киткән илләрдәге күрсәткечтән 5 тапкырга күбрәк. Британия галимнәре гомер озынлыгының генетик факторларга һәм әйләнә-тирә мохит үзенчәлекләренә никадәр бәйле булуын ачыкларга тели. Алынган мәгълүматлар картаюны әкренәйтә торган дарулар ясауда кулланылачак. Әлегрәк Сардиния халкының озын гомерле булуын аларның нигездә яшелчә, җиләк-җимеш һәм балык ашауларына гына бәйләп аңлатканнар. Әмма бу Урта диңгез диетасы күп илләрдә популяр, тик аларның берсендә дә халык шулкадәр озак яшәми.

(“The Local”).

Озын гомерлеләр арта

